пограничная ~ чик буе заставасы

затвор *м* 1. затвор, бик, йозак
~ **винтовки** винтовка затворы
затемнение *с* (яктылыкны) томалау (каплау)
затемнить томаларга; карангыларга
затопить батырырга; су басу
захватить басып алырга, алырга
захоронить күмеп (җирләп) куярга
зачислить кабул итәргә
защита *ж* саклау, саклану
защитить сакларга, якларга
защитник *м* саклаучы, яклаучы
заявка *ж* гариза, таләп
~ **на топливо** ягулык гаризасы
звание *с* исем, дәрәҗә
звено *с* 1. буын, боҗра 2. звено, бүлек
звуковой тавыш ...ы, е; тавышлы
звукопроводность *ж* тавыш үткәрүчәнлек
звукопроницаемый тавыш үткәрүчән
звукоулавливатель *м* тавыш тоткыч
землеройный жир казу ...ы, е
зенитн//ый зенит ...ы, е
~**ая артиллерия** зенит артиллериясе
зенитчик *м* зенитчы
зигзагообразный зигзагсыман
знак *м* билге, тамга, ым, ишарә
~**и отличия** тану билгеләре
~**и различия** дәрәҗә билгеләре
условные ~**и** шартлы билгеләр
знамя *ж* байрак, әләм
зоман *м* зоман *(агулы матдә)*
зона *ж* зона
запретная ~ тыелган зона
~ **наблюдения** күзәтү зонасы
нейтральная ~ нейтраль зона
пограничная ~ чик буе зонасы
зонд *м* зонд *(1. кешенең ашказаны суын алу яки ашказанын юдыру өчен кулланыла торган көпшә 2. һава шартларын тикшерә торган шар)*
зондировать 1. зонд белән тикшерергә 2. алдан сынап карарга, чамалап карарга
зрительн//ый күрү ...ы, карау ...ы, е
~**ая память** күрү хәтере
~**ая труба** карау торбасы *(якынайтып күрсәтүче торба)*
зыбь *ж* җыерчык, вак дулкыннар

И

игра *ж* уен
военная ~ хәрби уен
изготовлять әзерләргә, ясарга, эшләп чыгарырга
излишек *м* артыгы, калдык
излучение *с* нурланыш; нурлану, нур сибү (чәчү, тарату)
направленное ~ юнәлешле нурлану
радиоактивное ~ радиоактив нурланыш
излучина *ж* борылыш, борылма *(елгада)*
измотаться хәлдән таярга, арырга, алҗырга
измена *ж* хыянәт, сату, сатылу
~ **родине** ватанга хыянәт
государственная ~ дәүләткә хыянәт
изменник *м* хыянәтче, сатлык жан, хаин
износиться таушалырга, тузып бетәргә
изнуренный йончыган, талчыккан, арыган
изнурительный хәлдән тайдыргыч, йончыткыч
изолятор *м* изолятор *(1. үзе аркылы электр тогы үткәрми торган матдә 2. кулга алынучыларны урнаштыру урыны)*
изоляция *ж* изоляция
иллюминатор *м* иллюминатор *(суднода, самолетта, космик корабта һ.б. тәрәзә)*
имитация *ж* имитация *(маскировка алымы)*
имитировать *ж* имитацияләргә, охшатып ясарга
иммельман *м* иммельман *(немец очучысы М.Иммельман исеме белән аталган югары пилотаж фигурасы)*
имущество *с* милек, мөлкәт
инвалид *м* инвалид *(авыру яки имгәну сәбәпле хезмәткә яраклылыгын өлешчә яки тулысынча югалткан кеше)*
~ **войны** сугыш инвалиды
инвентарь *м* инвентарь *(эш кораллары, җиһазлары, җитештеру чаралары)*
индикатор *м* индикатор *(нинди дә булса процессларны күрсәтә торган прибор яки матдә)*
инициатив//а *ж* башлангыч, инициатива *(башлап йөрү, берәр эшне башлап җибәрергә этәргеч бирү)*
законодательная ~**а** закон чыгару инициативасы
проявить ~**у** инициатива күрсәтергә
инспектировать инспекция ясарга
инспектор *м* инспектор, тикшерүче
инстанция *ж* инстанция *(бер-беренә буйсынган дәүләт органнары, учреждениеләре системасының аерым баскычы)*

институт *м* институт
авиационный ~ авиация институты
военный ~ хәрби институт
инструктаж *м* инструктаж, инструкция бирү, күрсәтмәләр бирү
инструкция *ж* инструкция, күрсәтмәләр
инструмент *м* инструмент, корал, әсбап
интендант *м* интендант *(хәрби хуҗалыкны алып баручы һәм армияне кирәк-ярак белән тәэмин итүче хәрби хезмәткәр)*
интендантство *с* интендантлык *(армияне кирәк-ярак белән тәэмин итә һәм хәрби хуҗалыкны алып бара торган оешма)*
интенсивный интенсив, киеренке
интервал *м* интервал, ара
интервент *м* интервент *(интервенциядә катнашучы)*
интервенция *ж* интервенция *(бер яки берничә дәүләтнең коралны көч кулланып икенче дәүләтнең эчке эшләренә катышуы)*
информация *ж* информация, мәгълүмат, белешмә, хәбәр
информировать хәбәр итәргә, информация бирергә, (хәбәр) җиткерергә
инфракрасн//ый инфракызыл
~**ое излучение** инфракызыл нурланыш
ионосфера *ж* ионосфера *(атмосфераның 50—80 километрдан башлап югарыгы өлеше)*
иприт *м* иприт *(агулы газ)*
искусство *с* осталык, сәнгать
испытание *с* 1. сынау, тикшерү 2. имтихан, сынау
испытать 1. сынарга, тикшерергә 2. (баштан) кичерергә, (баштан) үткәрергә, татырга
~ **мотор** моторны сынап карарга
исследование *с* тикшерү, карау, (фәнни) тикшеренү
исстрелять 1. атып бетерергә, атуга тотып бетерергә 2. атып тишкәләп бетерергә
исступление *с* чиксез ярсу, шашыну, котыру
истинный чын, чынбарлыктагы, дөрес, хак
источник *м* чыганак
~ **питания,** ~ **тока** ток чыганагы
истребитель *м* истребитель *(1. хәрби очкыч, һава сугышында дошман очкычларын юк итү өчен файдаланыла торган җиңел, тиз йөрешле һәм яхшы коралланган сугыш очкычы 2. дошманның сугыш техникасын (мәс., танк, туп һ.б.) юк итү өчен билгеләнгән хәрби хезмәткәр*
исход *м* тәмамлану, бетү; нәтиҗә
~ **боя** сугыш нәтиҗәсе
исходн//ый башлангыч, баштагы
~**ый пункт** башлангыч пункт
~**ая точка зрения** баштагы караш
исцелить савыктырырга, сәламәтләндерергә, терелтергә
исчезнуть юкка чыгарга, юк булырга, бетәргә
исчерпывающий тулы
~ **ответ** тулы җавап
исчисление *с* исәпләү, исәпләп чыгару
итог *м* нәтиҗә, йомгак
итоговы//й 1. барлык, бөтен 2. йомгак ...ы, е; йомгаклау ...ы, е
~**е занятия** йомгаклау дәресләре

К

кабель *м* кабель *(электр энергиясе тапшыру, сигнализация һәм элемтә урнаштыру өчен тышкы тәэсирләрдән саклый торган герметик тышчалы, бер яки берничә җепле тимерчыбык)*
полевой телефонный ~ кыр телефоны кабеле
кабельтов *м* кабельтов *(1. диңгездә 185,2 м озынлыгындагы үлчәү берәмлеге 2. 150 ммдан 350 ммга кадәр юанлыкта, киндер сүсеннән ишелгән, судноларда кулланыла торган трос)*
кабрирование *с* кабрирлау *(очып баручы самолетны аркылы күчәре тирәли бору, шулчагында самолетның борыны күтәрелә, бу маневр бомба ташлаганда кулланыла)*
кавалерия *ж* кавалерия, атлы гаскәр
кавалькада *ж* кавалькада *(бәйрәмнәрдә, тантаналарда атлы җайдаклар төркеме)*
казарма *ж* казарма *(1. хәрби частьларны урнаштыру өчен махсус бина 2. 1917 елга кадәр фабрикалар, промыселлар һ.б. карамагындагы эшчеләр тулай торагы)*
казачий *м* 1. казаклар ...ы, е; ~ **атаман** казаклар атаманы 2. *м разг.* ка-

зачий *(казаклар гаскәрендәге рядовой)*

каземат *м* каземат *(1. артиллерия һәм авиация утыннан саклану, орудиеләр һәм пулеметлар кую, сугыш кирәк-яраклары саклау өчен бетон корылма 2. төрмәдәге камера)*

казённик *м* казённик *(туп, миномет көпшәсенең арткы өлеше)*

калибр *м* калибр *(ату коралы көпшәсенең эчке диаметры)*

калориметр *м* калориметр *(җылылык микъдарын үлчәү приборы)*

камбуз *м* камбуз *(корабтагы кухня)*

камикадзе *с* камикадзе *(икенче бөтендөнья сугышы вакытында (1939—1945) япон авиациясендә цельне атакалаучы очкычы белән бергә һәлак булучы очучы — үлемдар)*

кампания *ж* кампания *(билгеле бер урында барган кыска вакытлы сугыш)*

камуфлет *м* камуфлет *(артиллерия снарядларының, миналарның, авиабомбаларның чокыр ясамыйча җир астында шартлавы)*

камуфляж *м* камуфляж *(орудиеләрне, корабларны, биналарны һ.б. төрле сызыклар, таплар һ.б. төшереп дошманнан яшерү)*

канал *м* канал, куышлык

~ **ствола** көпшә куышлыгы *(мылтык, туп көпшәсендә)*

канонада *ж* канонада *(күпсанлы туплардан еш-еш ату һәм шуннан ишетелгән гүләү тавышы)*

канонир *м* канонир *(XIX йөздә Россиядә артиллерия солдаты, тупчы солдат)*

кант *м* кант *(хәрби хезмәткәрләр киеменең кырыйларына яки җөенә тегелгән төсле кәйтән)*

капитан *м* капитан

капитулировать капитуляция ясарга, корал ташларга

капитуляция *ж* капитуляция *(сугышта җиңгән як куйган шартларга риза булып, җиңелгән якның бирелүе, корал ташлавы)*

капонир *м* капонир *(1. капма-каршы ут ачарга мөмкинлек бирә торган саклану корылмасы 2. очкычларны яшерү урыны)*

капотировать баш аркылы өйләнергә *(очкычлар белән була торган авариянең бер төре)*

капрал *м* капрал *(кайбер илләрнең армияләрендә һәм XVII йөздән XIX йөзгә кадәр рус армиясендә кече командирлар (унтер-офицерлар) составы дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәгә ия булган кеше)*

капсюль *м* капсюль (көпсел) *(патроннар һ.б.ларның зарядын кабызучы, бәрүдән шартлап китә торган матдәле металл калпак)*

карабин *м* карабин *(кыскартылган һәм җиңеләйтелгән винтовка. Кубесенчә атлы гаскәрләрдә һәм артиллериядә кулланыла)*

караул *м* каравыл *(коралла дежурлык, сакта тору)*

выставить ~ каравыл куярга

назначить в ~ каравылга билгеләргә

нести ~ каравыл торырга

почетный ~ почетлы каравыл

сменить ~ каравылны алмаштырырга

караульный *м* каравылчы

картечь *м* картечь *(1. вак-вак йомры һәм яссы кургаш кисәкләре тутырылган артиллерия снаряды 2. ау мылтыклары өчен диаметры 5 ммдан эрерәк булган ядрә)*

картограф *м* картограф *(карта төшерү белгече)*

карточка *ж* карточка

~ **взысканий и поощрений** шелтәләр һәм бүләкләүләр карточкасы

служебная ~ хезмәт карточкасы

учетная ~ исәп карточкасы

каска *ж* каска *(башны пулялардан, ярчыклардан, бәрү-сугулардан саклау өчен металлдан, пластмассадан һ.б. материалдан ясалган тирән баш киеме)*

катализатор *м* катализатор *(химик реакцияне тизләтеп үзе үзгәрешсез кала торган матдә)*

катапульта *ж* катапульта *(1. кораб палубасыннан очкычларны очыртып җибәрү җайланмасы 2. очкыч аппаратлардан экипажны читкә атып чыгара торган автомат коткару җайланмасы 3. борынгы заманда дошманга таш, ук һ.б. ату җайланмасы)*

катапультирование *с* катапульцияләү, катапульция ясау

катастрофа һәлакәт, катастрофа, каза, афәт

катастрофический һәлакәтле, катастрофик, казалы, афәтле

качка *ж* чайкалу
бортовая ~ ян-якка чайкалу
вертикальная ~ вертикаль чайкалу
килевая ~ буйга чайкалу
каюта *ж* каюта *(суднодагы бүлмә)*
кают-компания *ж* кают-компания *(суднода командирларның ашау-эчү, ял итү бүлмәсе)*
квадрант *м* квадрант *(артиллерия орудиеләрен төзәгәндә почмак үлчәү приборы)*
квартирьер *м* квартирьер *(гаскәр бер урыннан икенче урынга күчкәндә, алдан барып фатир әзерләп торучы хәрби кеше)*
керосин *м* керосин *(нефтьне кудырып алына торган сыек ягулык)*
кессон *м* кессон *(елга яки диңгез төбенә төшеп эшләгәндә кулланыла торган су уткәрмәүчән зур камера)*
килектор *м* килектор *(көчле йөк күтәрү җайланмалары белән җиһазланган судно)*
киль *м* киль *(кораб корпусының аскы буй өрлеге)*
кильватер *м* кильватер *(хәрәкәт итүче кораб артында кала торган эз)*
кингстон *м* кингстон *(корабның су асты өлешендә кораб эченә төрле максатлар өчен су кертә торган каплавычлы тишек)*
класс *м* класс, дәрәҗә
каюта второго ~а икенче класслы каюта
специалист высшего ~а югары дәрәҗәле белгеч
классность (классная квалификация) *ж* класслылык (класслы белгечлек)
клинок *м* 1. кылыч йөзе 2. кылыч
клиренс *м* клиренс *(җир белән машина корпусы арасы)*
кнехт *м* кнехт *(кораб палубасында яки пристаньда аркан бәйләү өчен тәбәнәк юан багана)*
книга *ж* 1. китап 2. кенәгә
медицинская ~ медицина кенәгәсе
кобура *ж* кобура *(пистолет, маузер, револьвер яки наган кынысы, кабы)*
код *м* код *(телефон, телеграф, радио һ.б. аша белешмәләр, сигналлар бирү өчен кулланыла торган шартлы кыскартмалар, билгеләр системасы)*
шифровальный ~ шифр коды
кожух *м* япма
колебание *с* тирбәлү, селкенү, дулкынлану
коллектор *м* коллектор *(1. төрле торбалардан килгән сыекчаларны, газларны җыеп, кая да булса җибәрү өчен канал яки юан торба 2. динамомашинада алмаш токны даими токка әйләндерү җайланмасы)*
коллиматор *м* коллиматор *(ракетаны, артиллерия орудиесен панорама кулланып цельгә горизонталь төбәү өчен оптик җайланма)*
колонна *ж* колонна
кольцо *с* боҗра, алка, балдак
~ **блокады** блокада боҗрасы
~ **парашюта** парашют алкасы
поршневое ~ пешкәк балдагы
команд//а *ж* 1. команда, боерык 2. команда, төркем
~ **корабля** кораб командасы
подавать ~у команда бирергә
спасательная ~ коткару командасы
командир *м* командир
вышестоящий ~ югарыгы командир
строевой ~ строевой командир
командировать командировкага җибәрергә
командн//ый 1. командир(лык) ...ы, е; командир(лар) ...ы, е
~ **ый состав** командирлар составы
2. өстен, өстенлек итүче
~ые высоты иң биек урыннар
командование *с* 1. командалык итү, җитәкчелек итү 2. командалык, командирлар
~ **полка** полк командирлары
~ **полком** полк белән командалык итү
командовать 1. команда бирергә 2. командалык итәргә, боерык бирергә
командующий *м* командующий *(1. зур гаскәри берләшмә башлыгы 2. командалык итүче)*
комендант *м* комендант *(1. хәрби крепость яки ныгытылган районның башлыгы 2. хәрби хезмәткәрләрнең җәмәгать урыннарында үз-үзләрен тотуларын күзәтү кебек эшләргә җи-тәкчелек итүче хәрби башлык 3. аралашу юлларында гаскәрнең, хәрбиләрнең һәм хәрби йөкләрнең дөрес хәрәкәт итүен күзәтеп торучы)*
комендатура *ж* комендатура *(комендант җитәкчелегендәге учреждение, шул учреждение урнашкан бина)*
комендор *м* комендор *(матрос-артиллерист)*

комиссариат *м* комиссариат
военный ~ хәрби комиссариат
комиссия *ж* комиссия
призывная ~ хәрби хезмәткә алу комиссиясе
коммуникация *ж* коммуникация, элемтә *(армия белән аның базалары арасында аралашу юллары)*
коммутатор *м* коммутатор *(1. электр тогы линиясен тоташтыру һәм өзү, шулай ук токның юнәлешен үзгәртү приборы 2. телефон станцияләрендә, оешмаларда абонентларны тоташтыру үзәге)*
ко мне! *(команда)* минем янга!
компенсатор *м* компенсатор *(нинди дә булса механизмның эшен тигезләү өчен билгеләнгән приборларның җыелма атамасы)*
комплект *м* комплект *(1. билгеле бер максатка хезмәт итә торган предметларның тулы җыелмасы 2. инструкция яки штат буенча берәр җиргә кабул ителә, урнаштырыла торган кешеләрнең тулы саны)*
комплектовать комплектларга, тупларга
компонент *м* компонент *(состав өлеш)*
конвекция *ж* конвекция *(җылылык яки электр корылмаларының хәрәкәтчән тирәлек ярдәмендә күченүе)*
конвертоплан *м* конвертоплан *(самолет һәм вертолет сыйфатларын берләштерә торган очу аппараты)*
конвой *м* конвой *(1.тоткыннарны, әсирләрне саклап озата баручы кораллы отряд 2. сәүдә судноларын дошманнан саклап озата бара торган судолар яки очкычлар)*
контингент *м* контингент *(1. нинди дә булса мөнәсәбәтләрдә бер төрле кешеләр төркеме, мәс., хәрби академия тыңлаучылары контингенты 2. нәрсәгә дә булса куелган чик, норма)*
контрабанда *ж* контрабанда *(пошлина салына торган яки чыгару тыелган товарларны яшерен рәвештә бер илдән икенче илгә чыгару, шулай чыгарылган товарлар)*
контр-адмирал *м* контр-адмирал *(хәрби флотта адмиралдан ике чинга түбәнрәк дәрәҗә)*
контракт *м* контракт *(язма килешү)*
контратака *ж* контратака, каршы һөҗүм
контратаковать контратака ясарга, каршы һөҗүм итәргә
контрманевр *м* каршы маневр
контрмина *ж* контрмина *(саклану корылмаларына якын юлларны дошман минерларыннан саклау өчен куелган мина)*
контроль *м* контроль, күзәтеп тору, тикшерү
контрразведка *ж* контрразведка *(дошман разведкасына, шпионнарына, диверсантларына каршы хәрәкәт итә, көрәшә торган махсус оешма)*
контрудар *м* контрудар, каршы һөҗүм
контузия *ж* контузия *(якында гына снаряд яки бомба шартлау нәтиҗәсендә организмның берәр кисәгенең тыштан яраланмыйча гына имгәнүе)*
концентрация *ж* 1. җыю, туплау, тупланыш 2. концентрация *(куелык дәрәҗәсе)*
концентрировать 1. җыярга, тупларга 2. юнәлтергә, юнәлдерергә 3. куертырга, баектырырга
~ **внимание** игътибарны юнәлтергә
~ **войска** гаскәрләрне тупларга
координация *ж* 1. координацияләү, яраштыру, яраклаштыру, килештерү 2. координация, үзара килешкәнлек, ярашканлык
копёр *м* копёр *(субай сугу машинасы)*
копье *с* сөңге
корабль *м* кораб
боевой ~ хәрби кораб
космический ~ космик кораб
~ **-спутник** иярчен кораб *(орбитага чыгарылган космик кораб)*
корвет *м* корвет *(өч мачталы, җилкәнле борынгы хәрби кораб)*
кордон *м* кордон *(юлны саклап торучылар яки чик сакчылары отряды)*
корма *ж* койрык өлеш *(корабның, транспорт очкычының)*
коробка *ж* тартма, кап
коротковолновый кыска дулкынлы *(радиоалгыч)*
короче шаг! *(команда)* кыскарак атла!
корпус *м* 1. корпус 2. гәүдә
корректировать төзәтергә, дөресләргә, корректива ясарга
~ **стрельбу** атуны дөресләргә
корреспондент *м* корреспондент, хәбәрче
кортик *м* хәнҗәр, кортик *(һава һәм диңгез флотында адмиралларның, генералларның, офицерларның һәм мичманнарның форма киеме элементы)*

космос *м* галәм, космос
котелок *м* котелок *(гаскәринең үзе белән йөртә торган тоткалы кечкенә металл савыт)*
котлован *м* котлован *(тирән чокыр)*
кошка *ж* япьле ыргак
коэффициент *м* коэффициент
~ **полезного действия** файдалы эш коэффициенты
крейсер *м* крейсер *(ракета комплекслары белән җиһазланган зур сугыш корабы)*
крейсировать хәрби күзәтү алып барырга *(диңгездә, елгада)*
крен *м* янтаю, кырынаю
кренить янтайтырга, кырынайтырга
крепость *ж* крепость, кирмән, ныгытма, кальга
летающая ~ оча торган крепость *(ерак арага очучы бомбардировщик турында)*
кривая *ж* кәкре сызык
кронциркуль *м* кронциркуль *(бик кечкенә түгәрәкләр сызу өчен кулланыла торган циркуль)*
кругом! *(команда)* әйлән!
крупнокалиберный эре калибрлы
крутизна *ж* текәлек
крючок *м* тәте *(мылтык, пистолет һ.б. ату коралында бәрмә механизм кисәге; чакма)*
спусковой ~ ычкындыру тәтесе
кубрик *м* кубрик *(корабның команда урнашкан өлеше)*
курок *м* курок, тәте, чакма
курс *м* курс, юл
лететь по ~у курс буенча очарга
отклоняться от ~а курстан тайпылырга
курсант *м* курсант *(хәрби уку йортында белем алучы)*
кухня *ж* кухня, аш бүлмәсе
полевая ~ кыр кухнясы *(кырда ашсу пешерү өчен махсус җайланма)*
кучность *ж* оешлык
~ **попадания пуль** пулялар тию оешлыгы
кювет *м* кювет *(крепость стенасы янындагы су тутырылган канау)*

Л

лаборатория *ж* лаборатория
орбитально-космическая ~ орбиталь-космик лаборатория
полевая ~ кыр лабораториясе
лавировать борыла-сарыла барырга
лаг *м* лаг *(судноның йөрү тизлеген күрсәтә торган прибор)*
лагерь *м* лагерь
концентрационный ~ концентрацион лагерь
лагуна *ж* лагуна, диңгез култыгы
лайнер *м* лайнер *(1. зур диңгез судносы 2. күп урынлы самолет)*
лакриматор *м* лакриматор *(күздән яшь агыза торган матдә)*
лампас *м* лампас *(форма чалбарына буйдан-буйга тегелә торган төсле тасма)*
латник *м* көбә кигән сугышчы
латы *мн.* көбә *(борынгы заманда салкын коралдан саклану өчен гаскәриләр кия торган корыч кием)*
лафет *м* лафет *(артиллерия орудиесе беркетеп куела торган станок, җайланма)*
лебедка *ж* лебедка, чыгыр *(йөкләрне күтәрү һәм урыннан-урынга күчерү өчен махсус җайланма)*
левофланговый сул флангтагы
легенда *ж* легенда *(картага, рәсемгә аңлатма)*
легкораненый җиңел яралы
ледокол *м* бозваткыч
леер *м* леер *(корабларда ябышып йөрү өчен ике очы ике якка беркетелеп бик нык тарттырылган бау яки трос)*
лежень *м* ятма бүрәнә, ятма борыс *(берәр нәрсә астына нигез итеп салынган бүрәнә, борыс)*
лейб-гвардия *ж* лейб-гвардия *(башында монарх торган кайбер дәүләтләрдә үзенә аерым өстен хокуклары булган гаскәр; элек патшаның тән сакчыларын шулай атаганнар)*
лейтенант *м* лейтенант
младший ~ кече лейтенант
старший ~ өлкән лейтенант
лента *ж* тасма
летчик *м* очучы
лечение *с* дәвалау, дәвалану
лидер *м* лидер, әйдәп баручы, алдан баручы
лиман *м* лиман *(елгаларның диңгезгә койган урыннарында барлыкка килгән култык)*
лимб *м* лимб *(приборларда градусларга бүленгән түгәрәк)*
лимит *м* лимит, чик норма

линейка *ж* линейка, чик сызык
лини//я *ж* 1. сызык 2. юнәлеш, юл 3. саф, рәт 4. линия, юл
~я железной дороги тимер юл линиясе
~я полета снаряда снарядның очу сызыгы
~я фронта фронт сызыгы
провести ~ю сызык сызарга
лист *м* табак
~ железа бер табак калай
лихтер *м* лихтер *(баржа тибындагы кечкенә судно)*
ловушка *ж* тозак
лодка *ж* көймә
ложись! *(команда)* ят!
ложный ялган
локальный локаль, җирле *(билгеле бер урынга хас)*
лопасть *ж* калак, канат
~ воздушного винта һава винты канаты
лопата *ж* көрәк
саперная ~ сапер көрәге
лоция *ж* лоция *(1. кораблар йөртү турындагы фән 2. диңгезләр, елгалар һәм яр буйлары турындагы мәгълүматларны эченә алган белешмәләр китабы)*
лоцман *м* лоцман *(фарватерны яхшы белүче һәм аннан судноллар үткәрүче белгеч)*
лощина *ж* уйсулык, уйсу җир, инкүлек
лунка *ж (для мин)* чокырчык
люизит *м* люизит *(төссез сыекчадан гыйбарәт тотрыклы агулы матдә)*
люк *м* люк *(1. суднода, очкычта: ату коралы өчен тишек; очкычта: бомба ташлау тишеге 2. танкта: эчкә керү, түбәнгә төшү өчен капкач белән ябыла торган тишек)*
люлька *ж* люлька *(артиллерия орудиесе лафетының бер өлеше)*
лютый кансыз, явыз, ерткыч
~ враг явыз дошман
лязгнуть чыңгылдап, чыкылдап куярга

М

магазин *м* магазин *(аппаратларда, приборларда, ату коралларында бер төрле берничә әйбер салу өчен хезмәт итә торган җайланма — тартма, диск, көпшә һ.б.)*
~ барабанного типа барабан тибындагы магазин
дисковый ~ дисксыман магазин
коробчатый ~ тартмасыман магазин
майор *м* майор
малогабаритный кече габаритлы
малолитражный кече литражлы
манёвр *м* манёвр *(сугыш вакытында гаскәрләрнең дошманга һөҗүм итү өчен җайлырак булган урынга күчүләре)*
маневренный маневрлы
манёвры *мн.* манёврлар *(гаскәрләрнең сугыш шартларына якынайтылган хәлдә тактик өйрәнү үткәрүләре)*
манометр *м* манометр *(ябык савыт эчендәге газ яки сыеклыкның басымын үлчи торган прибор)*
маркировка *ж* тамга, тамгалау
мародер *м* мародер *(сугыш кырында яралы яки үлгән сугышчыларның әйберләрен талаучы)*
мародерство *с* мародерлык
мародерствовать мародерлык итәргә
марш! *м (хәрби команда)* марш, кузгал!
строевым шагом ~! *(команда)* саф адымы белән марш!
шагом ~! *(команда)* атлап марш!
маршал *м* маршал
маска *ж* битлек
маскировать маскировкаларга, яшерергә, капларга
маскировка *ж* маскировка *(ныгытмаларны, коралларны һ.б. дошманнан яшерү өчен кулланыла торган әйберләр)*
массированный юнәлтелгән, куәтле
~ налет авиации авиациянең куәтле һөҗүме
мастерство *с* осталык
боевое ~ сугышчан осталык
матрос *м* матрос
маховик *м* маховик *(двигательләрнең тигез әйләнүен тәэмин итү өчен двигатель валына кидерелгән зур массалы тәгәрмәч)*
маяк *м* маяк
маятник *м* 1. маятник 2. сәгать теле
медаль *ж* медаль *(нинди дә булса сурәте, язуы булган һәм зур хезмәт күрсәткечләре яки сугыштагы батырлыклар өчен бирелә торган металл түгәрәктән гыйбарәт билге)*
медсестра *ж* медсестра, шәфкать туташы

мелкокалиберный вак калибрлы
мер//а *ж* 1. чара 2. чама
~ы безопасности куркынычсызлык чаралары
мероприятие *с* чара
местность *ж* урын, җир, як
местонахождение *с* урын, табылу урыны, чыга торган урын
метеоролог *м* метеоролог, метеорология белгече
метеорологический метеорология ...ы, метеорологик
метеорология *ж* метеорология *(һава торышы һәм атмосферада була торган күренешләр турындагы фән)*
метк//ий төз, туры
~ий стрелок төз атучы, мәргән
~ий удар туры сугу
~ое попадание туры тидерү
метод *м* метод, алым, ысул, юл
механизированн//ый 1. механикалаштырылган 2. машиналар белән тәэмин ителгән
~ые войска машиналар белән тәэмин ителгән гаскәр
механик *м* механик *(1. механика белгече 2. машиналарның дөрес эшләвен күзәтүче инженер, техник яки эшче)*
механик-водитель *м* механик-йөртүче
мешок *м* 1. капчык 2. чолганыш, капчык *(зур төркем гаскәрнең тулы чолганышта калуы)*
вещевой ~ әйбер капчыгы
мидель *м* мидель *(корабның иң киң өлеше)*
мидель-шпангоут *м* мидель-шпангоут *(судноның иң киң өлешенә куелган аркылы борыс)*
милитаризация *ж* милитаризация *(экономик, сәяси һәм иҗтимагый тормышны басып алу сугышы максатларына буйсындыру)*
милитаризм *м* милитаризм *(кораллануга, сугышка әзерләнүгә юнәлтелгән реакцион агрессив сәясәт)*
миля *ж* миль
морская ~ диңгез миле *(1852 метр)*
минер *м* минер *(1. миначы 2. хәрби корабта миналы коралларга хезмәт күрсәтүче белгеч)*
минировать мина куярга, миналарга
министерство *с* министрлык
~ обороны оборона министрлыгы
министр *м* министр
~ обороны оборона министры

минн//ый мина(лар) ...ы, е
~ое поле миналар кыры
миноискатель *м* мина эзләгеч
миномет *м* миномет
минометчик *м* минометчы
миноносец *м* миноносец *(торпедалар белән коралланган хәрби кораб)*
минреп *м* минреп *(якорьлы диңгез минасын су өстеннән билгеләнгән ераклыкта тоту өчен махсус трос, чыбыр)*
мир *м* 1. тынычлык 2. солых
мишен//ь *ж* мишень, мәрә *(реаль цельнең аеруча характерлы билгеләрен имитацияләүче ясалма цель)*
«яблочко» ~и мишень «алмасы» *(мишеньнең кара түгәрәк итеп ясалган үзәге)*
мобилизация *ж* мобилизация, мобилизацияләү *(тыныч вакыттагы барлык кораллы көчләрне сугышчан хәлгә күчерү. Халык хуҗалыгының барлык өлкәләрен хәрби хәлгә күчерү)*
мобилизовать мобилизацияләргә, мобилизация ясарга
мобильность *ж* хәрәкәтчәнлек
мобильный тиз хәрәкәтчән, мобиль
модернизация *ж* яңарту, камилләштерү, модернизация
модуляция *ж* модуляция *(зур ешлыклы тирбәнешләрне кече ешлыклы тавыш яки башка сигнал тирбәнешләренә туры китерү процессы)*
момент *м* момент, мизгел
монитор *м* монитор *(яр буендагы объектларга һөҗүм итү өчен файдаланыла торган авыр артиллерияле сугыш корабы)*
монокок *м* монокок *(самолет конструкциясенең бер төре)*
монтаж *м* монтаж *(1. берәр нәрсәнең аерым кисәкләрен бер тәртип белән тезеп, бербөтен хәлгә китерү 2. машинаны, җайланманы яки корылманы җыеп эшкә көйләү)*
мореходность *ж* йөзә алучанлык *(диңгез кораблары турында)*
мореходн//ый диңгез ...ы, е; диңгез челек ...ы, е
~ое училище диңгез училищесы
мортира *ж* мортира *(эре калибрлы, кыска көпшәле артиллерия тубы)*
моряк *м* диңгезче, моряк
мостик *м* күперчек, басма
капитанский ~ капитан күперчеге

мощность *ж* егәрлек, куәт
мощь *ж* көч, куәт, егәр
мундир *м* мундир
парадный ~ парад мундиры
муфта *ж* муфта *(машина частьларын, торба очларын һ.б. узара тоташтыру өчен кулланыла торган җайланма)*
мушка *ж* мушка *(төзәп ату өчен мылтык көпшәсе очына ясалган чыгынты)*
мыс *м* борын
мятеж *м* фетнә, чуалыш, баш күтәрү

Н

набег *м* баскын, һөҗүм
совершать ~ һөҗүм ясарга
наблюдатель *м* күзәтче, күзәтүче
наблюдать күзәтергә
наблюдение *с* күзәтү
набор *м* 1. жыю, кабул итү, алу 2. жыелма
наведение *с* юнәлтү, турылау, төзәү, төбәү
навигация *ж* навигация *(1. кораблар йөртү фәне һәм сәнгате 2. елның кораблар йөри ала торган вакыты, сезоны 3. кораблар йөреше)*
наводить 1. юнәлтергә, турыларга, төзәргә, төбәргә 2. салырга, төзергә
наводчик *м* 1. төзәүче 2. юнәлтүче
наган *м* наган *(Бельгия корал остасы Л.Наган исеме белән аталган 7,62 мм калибрлы револьвер)*
нагар *м* корым, ыс, көек
нагарообразование *с* корым утыру, ыслану
нагнетатель *м* һава кудыргыч
наград//а *ж* награда, бүләк
представить к ~е бүләккә тәкъдим итәргә
посмертная ~а үлгәннән соң бүләкләү
награждать бүләкләргә, бүләк бирергә
нагрузка *ж* 1. йөкләнеш 2. төяү, йөкләү
надводный су өсте ...ы, е; су өстендәге
~ **флот** су өсте флоты
надежность *ж* ышанычлылык
надолба *ж* кыска багана
назначать билгеләргә, куярга
назначение *с* 1. билгеләү, кую 2. максат, бурыч
~ **в наряд** нарядка билгеләү
наказани//е *с* җәза, җәза бирү
подвергнуть ~ю җәзага тартырга
накат *м* накат *(1. орудиенең атканда артка таба хәрәкәтеннән соң алга таба китүе 2. өскә тезелгән бүрәнәләр, калын такталар катламы)*
накидка *ж* япма
наклон *м* авышлык, сөзәклек
налево! *(команда)* сулга!
~ **разомкнись!** *(команда)* сулга сирәклән!
~ **сомкнись!** *(команда)* сулга тыгызлан!
налет *м* һөҗүм, басу, талау
наличие *с* барлык, булу, бар булу
наличный булган, кулдагы, кулда булган
~ **состав армии** армиянең гамәлдәге составы
намерение *с* ният, теләк, исәп
на месте! *(команда)* урында!
нападение *с* һөҗүм итү, ташлану
воздушное ~ һава һөҗүме
вооруженное ~ коралды һөҗүм
напалм *м* напалм *(яндыргыч бомбалар, утаткычлар өчен составында бензин, керосин, органик кислоталарның алюминий тозлары булган койка сыман ябышкак катнашма. Яндыргычлар ярдәмендә тиз кабынып китә, ялкын температурасы 1100—1600°С)*
направление *с* юнәлеш, як
направо! *(команда)* уңга!
нарез *м* сыр, кирт
нарезной сырлы
~ **ствол** сырлы көпшә
нарочный *м* хәбәрче, атчабар *(әһәмиятле ашыгыч хәбәр яки йомыш белән җибәрелгән кеше)*
нарушение *с* бозу
нарушитель *м* бозучы
~ **границы** чик бозучы
~ **дисциплины** тәртип бозучы
наряд *м* наряд, кизү *(1. билгеле бер хезмәтне башкару өчен билгеләнгән подразделение яки гаскәрләр төркеме 2. хезмәт буенча кушылган билгеле бер эшне үтәү)*
быть в ~е нарядта булырга
заступить в ~ нарядка басарга
назначить в ~ нарядка билгеләргә
освобождать от ~а нарядтан азат итәргә
сменить ~ наряд алмаштырырга
~ **вне очереди** чираттан тыш наряд
~ **на работу** эшкә наряд
суточный ~ тәүлекле наряд
население *с* халык

местное ~ җирле халык
наставление *с* кулланма
техническое ~ техник кулланма
настил *м* түшәмә
наступательный һөҗүм ...ы, е
~ **бой** һөҗүм сугышы
наступление *с* һөҗүм, һөҗүм итү
натиск *м* кысрыклау, кысу
натренированность *ж* яхшы күнеккәнлек
начальник *м* башлык, начальник
непосредственный ~ турыдан-туры начальник
старший ~ өлкән начальник
нашивка *ж* нашивка *(погонга яки җиңгә тегеп куела торган билге)*
нащупывать табарга, эзләп табарга
~ **слабые места в обороне** оборонаның йомшак якларын табарга
неблагоприятный уңайсыз, җайсыз, тискәре, начар
небоеспособный сугышка сәләтсез
невесомость *ж* авырлыксызлык
невмешательство *с* тыгылмау, катнашмау
невооруженный коралсыз, коралланмаган
невыгодный отышсыз, җайсыз
негодный яраксыз
недисциплинированность *ж* тәртипсезлек
недолет *м* (очып, барып) җитмәү *(снаряд, пуля һ.б. турында)*
недоступный үтәрлек булмаган; керә алмаслык
незамаскированный яшерелмәгән
незаминированный миналанмаган, минасыз, мина куелмаган
незащищенный саклаусыз, сакланмаган
неисправность *ж* төзексезлек, ватыклык
нейтралитет *м* битарафлык, катнашмаучылык, нейтралитет
нейтрон *м* нейтрон *(атом төше составындагы корылмасыз кисәкчә)*
некомплектный комплектсыз, тулыландырылмаган
некомплектованный комплектланмаган, саны тулмаган
необстрелянный ут астында булмаган, сугышка кермәгән, сугыш күрмәгән
необученный өйрәтелмәгән
неопознанный танылмаган, ачыкланмаган
неповиновение *с* буйсынмау, баш бирмәү, тыңламау, карышу
неподчинение *с* буйсынмау, баш имәү
~ **приказу** боерыкка буйсынмау
непосредственный турыдан-туры
непреодолимый 1. җиңелмәс, җиңелми торган, җиңеп чыга алмаслык 2. үтә алмаслык
неприкрытый 1. ачыктан-ачык, яшерүсез 2. ябылмаган, капланмаган
неприступн//ый якын барырлык булмаган; һичкем ала алмаслык
~ **ая крепость** һичкем ала алмаслык крепость
неприятель *м* дошман
непробиваемый тишелми торган
непроходимый үтә (кичә) алмаслык, ерып чыкмаслык
нервюра *ж* нервюра *(самолет канатының бер элементы)*
нестойкий чыдамсыз, озак сакланмый торган
нестроевой сугышка яраксыз *(кеше)*, сугышка керми торган *(подразделение)*
нетоксичный агусыз
неуправляемый идарә ителми торган
неустойчивость *ж* 1. тотрыксызлык 2. үзгәрүчәнлек
неуязвим//ый зарарлау (җимерү, алу) мөмкин булмаган, ышанычлы, нык
~ **ая позиция** нык позиция
низменность *ж* түбәнлек, иңкүлек, уйсулык, үзәнлек
нитроцеллюлоза *ж* нитроцеллюлоза *(тиз кабынучан матдә)*
ниша *ж* куыш, уем, чокыр
новобранец *м* новобранец *(яңа гына хәрби хезмәткә алынган кеше)*
нок *м* нок *(һәрбер горизонталь яки авыш рангоут агачының очы)*
номенклатура *ж* номенклатура, исемлек
номер *м* номер, сан
нониус *м* нониус *(үлчәү инструментларының өстәмә шкаласы)*
норма *ж* норма, күләм
нос *м* борын *(көймәнең, корабның, очкычның алгы өлеше)*
носилки *только мн.* носилка *(авыр әйберләрне яки кешеләрне урыннан-урынга күчереп йөртү өчен кулланыла торган җайланма)*
нуклон *м* нуклон *(атом төшен тәшкил итүче кисәкчәләрнең уртак исеме)*

нумерация *ж* 1. номерлау, номерлар суѓу 2. номерлар
~ **частей** частьларның номерлары
нутация *ж* нутация *(тоткарсыз әйләнүче җисем күчәренең тирбәну хәрәкәте, чайкалуы)*
нюх *м* 1. ис тою сәләте 2. сизгерлек, сизем

О

обвести әйләндереп алырга, (койма) тотарга, киртәләргә
обезвреживание *с* зарарсызландыру
обезопасить куркынычтан (хәвеф-хәтәрдән) сакларга, куркынычсызлык тәэмин итәргә
обезоруживать коралсызландырырга
обеспечение *с* тәэмин итү, тәэминат
обеспеченность *ж* тәэмин ителгәнлек
обзор *м* 1. карап чыгу, күз йөртеп чыгу, күзәтү 2. күрү кинлеге, күрү мөмкинлеге
область *ж* өлкә, тирә
облачность *ж* болытлылык, болытлар
облет *м* очып әйләнеп чыгу; очып узып китү
облучение *с* нурлану, нурландыру, нурланыш
обмотки *мн.* чолгау
обмундирование *с* форма киеме
обнаружение *с* табу, ачыклау
обоз *м* обоз, олаулар
обойма *ж* обойма, патрон кысасы *(мылтык, пистолет яки автоматны берьюлы бернича патрон белән кору өчен магазин тартмасына урнаштырыла торган металл кыстыргыч)*
оболочка *ж* тышча, сүрү
оборона *ж* саклану, оборона *(1. билгеле бер урында, позициядә ныгып, дошманны тоткарлап, аның һөҗүмен кире кайтарып тору хәле 2. сугыш кырында һөҗүмнән саклану өчен кирәкле чаралар, корылмалар системасы 3. дошманның сугыш белән басып керүен кире кагарга, илнең куркынычсызлыгын тәэмин итәргә сәләтле чаралар җыелмасы)*
оборонять(ся) сакларга, оборонада торырга, оборона тотарга
оборудование *с* 1. җиһаз, жиһазлар 2. җиһазлау
обработка *ж* эшкәртү
образование *м* 1. белем 2. мәгариф
военное ~ хәрби белем
обслуживание *с* хезмәт күрсәтү
обстановка *ж* хәл, шартлар
обстрел *м* 1. утка тоту, атыш 2. ату зонасы, ут асты
быть под ~ом ут астында булырга
обстрелянный сугышта булган, сугыш күргән
обстрелять утка тотарга, тупка тотарга
обстреляться сугышка күнегергә
обтекаемость *ж* уңай агышлылык *(хәрәкәт иткәндә һаваның яки суның каршылыгына аз бирелүчән формада эшләнгән булу, мәс., уңай агышлы очкыч, автомобиль, көймә һ.б.)*
обтекаемый уңай агышлы
обтека//ть читләтеп агарга, орынып агарга, читләтеп үтәргә
воздух ~ет самолет һава очкычка орынып ага
река ~ет лес елга урманны читләтеп ага
обтюратор *м* обтюратор *(затворның бер өлеше)*
обучать, өйрәтергә, укытырга
обход *м* 1. әйләнеч юл, урау юл 2. читләтеп үтү, урап узу, уратып узу 3. *(маневр)* обход *(дошман урнашкан җиргә тирәнтен үтеп керу һәм аңа тылдан һөҗүм иту максатында уткәрелә)*
обшивка *ж* тышлык, тыш
общевойсковой гомумгаскәри
общение *с* аралашу, бәйләнеш, бәйләнеш тоту
объединение *с* берләшмә
объезд *м* 1. урау юл, әйләнеч юл 2. йөреп чыгу, карап чыгу
обыск *м* тентү
обязанность *ж* бурыч, вазифа
овладеть алырга, кулга төшерергә, үзләштерергә, ия булырга
~ **техникой** техниканы үзләштерергә
огнев//ой ут ...ы, е; ату ...ы, е
~ая точка ут ноктасы
~ые средства ату чаралары
огнемет *м* огнемет, утаткыч
огнеопасный тиз кабынучан
огнеприпасы ату кирәк-яраклары *(патрон, снаряд, бомба һ.б.)*
огнестойк//ий утка чыдам(лы)
~ие сооружения утка чыдамлы корылмалар
огнестрельн//ый ату ...ы, е; ата торган

~**ая рана** пуля (снаряд кыйпылчыгы) ярасы
~**ое оружие** ату коралы
огнетушитель *м* ут сүндергеч
огнеупорный утка чыдам(лы)
огонь *м* ут, атыш
открыть ~ ут ачарга
ограничитель *м* чиклəгеч
однополчанин *м* полкташ
одноствольный бер көпшəле
ожог *м* пешү, пешү ярасы
окаймлять тирəлəргə, уратырга, камарга
окисление *с* оксидлашу, окисьлашу
окислитель *м* оксидлаштыручы
оккупант *м* оккупант, илбасар, басып алучы
оккупация *ж* оккупация, басып алу
оккупировать оккупациялəргə, басып алырга
оклад *м* оклад, эш хакы, хезмəт хакы
оклик *м* эндəшү; эндəшү тавышы
окно *с* 1. тəрəзə 2. ачыклык (ачык урын)
окоп *м* окоп *(пуля, снаряд һ.б. тиюдəн саклану өчен тирəн һəм озын чокыр формасында казып, алдына балчык өеп эшлəнгəн ныгытма)*
окопаться *с* 1. окоп казып урнашырга 2. яшеренергə, качып ятарга
окраина *ж* кырый, чит, чик буе *(территориянең кырый өлеше)*
округ *м* округ
военный ~ хəрби округ
окружать камап (чолгап, əйлəндереп, уратып, сырып) алырга
окружение *с* 1. камап алу 2. камалыш, чолганыш
окуривание *с* төтəслəү, төтен җибəрү
опасность *ж* куркыныч, хəвеф-хəтəр
радиоактивная ~ радиоактив куркыныч
оперативность *ж* оперативлык, өлгерлек
оперативный 1. оператив *(мəс., киңəшмə)* 2. өлгер, җитез, оператив 3. *мед.* операция ...ы, е
операция *ж* операция *(берəр стратегик планны үтəүгə юнəлдерелгəн сугыш чаралары)*
совместная ~ катнаш операция, бергəлектəге операция
опись *ж* исемлек, опись *(əйберлəрне, милекне, документларны һ.б. исəпкə алу өчен төзелгəн исемлек)*
оповещать хəбəр итəргə, белдерергə
опознавание *с* тану
ополчение *с* ополчение *(регуляр армиягə ярдəм итү өчен күбесенчə ирекле рəвештə төзелгəн гаскəр)*
опора *ж* терəк, таяныч
опорн//ый терəк ...ы, е; таяныч ...ы, е; төп
~ **ая балка** төп өрлек
~ **ый пункт** терəк пункт
опреснитель *м* су төчелəндергеч
опрос *м* сорашу, җавап алу
оптический оптик, оптика ...ы, е
опушка *ж* урман буе (кырые, чите), урман авызы
орган *м* орган
~ **управления** идарə органы
организация *ж* 1. оештыру 2. оешма
орден *м* орден *(сугышта яки эштə күрсəткəн зур батырлыклар яки хезмəтлəр өчен бирелə торган махсус билге)*
~ **Красного Знамени** Кызыл Байрак ордены
~ **Красной Звезды** Кызыл Йолдыз ордены
~ **Отечественной войны** Ватан сугышы ордены
~ **Славы** Дан ордены
орденоносец *м* орденлы *(кеше яки оешма)*
орденская лента орден тасмасы
ординарец *м* ординарец *(командир янында яки штабта йомышлар үтəүче гаскəри)*
ориентир *м* ориентир *(урында хəрəкəт юнəлешен билгелəргə, кирəкле җирне тиз табарга ярдəм итə торган ачык билгеле нəрсə)*
ориентировать юнəлдерергə, юнəлеш бирергə
орудие *с* туп, орудие
дальнобойное ~ еракка ата торган орудие
~ **поддержки танков** танкларга ярдəм итүче орудие
самоходное ~ үзйөрешле туп
оружие *с* корал, сугыш коралы
нейтронное ~ нейтрон корал
стрелковое ~ ату коралы
применить ~ корал кулланырга
складывать ~ корал ташларга
осад//а *ж* камау, чолгау, камалыш, чолганыш
снимать ~**у** камауны алырга
осадка *ж* батым *(судноның суда утыру тирəнлеге)*
осадки явым-төшем

освещение *с* яктырту, яктылык
освидетельствование *с см.* освидетельствовать
освидетельствовать карарга, карап чыгарга, тикшереп чыгарга
освобождать 1. азат итәргә, ирекә чыгарырга 2. эштән (хезмәттән, вазифадан) бушатырга
осечк//а *ж* атмый калу, осечка
ружье дало ~у мылтык атмый калды, мылтык осечка бирде
осколок кыйпылчык, ярчык
минный ~ мина ярчыгы
осколочный ярчыклы, ярчык ...ы, е
ослепление *с* 1. сукырайту 2. күзне чагылдыру
осмотр *м* карау, тикшерү
врачебный ~ врач каравы, врач тикшерүе
оснастка *ж* 1. җиһаз, корал 2. җиһазлау, кораллындыру
оснащенность *ж* коралланыш, җиһазланыш, коралланган булу, җиһазланган булу
остойчивость *ж* тотрыклылык
~ корабля корабның тотрыклылыгы *(тышкы көчләр: дулкыннар, җил һ.б. басымы астында тотрыклы халдә калу сәләте)*
ось *ж* 1. күчәр 2. үзәк
отбивать кире кагарга, (сугышып) кире кайтарырга
~ город шәһәрне сугышып кире алырга
~ нападение һөҗүмне кире кагарга
отбой *м* отбой *(1. хәрби частьта (корабта) көн тәртибендә каралган сәгатьтә хезмәт итүчеләр составына йокыга киту өчен бирелә торган сигнал 2. хәрби хезмәткәрләрнең нинди дә булса шөгыльләрен, хәрәкәтләрен туктату өчен бирелә торган сигнал яисә команда)*
ответственност//ь *ж* җаваплылык
взять ~ь на себя җаваплылыкны үз өстенә алырга
привлечь к судебной ~и суд җаваплылыгына тартырга
ответчик *м* 1. җавап тотучы, җавапка тартылучы 2. җавапчы *(сорауларга яки шартлы сигналларга автоматик рәвештә җавап бирә торган кабул итү-тапшыру җайланмасы)*
отвлекать (читкә, үзенә) юнәлтергә, бүлдерергә

отвод *м* 1. алып китү, күчерү 2. аерып алу, читкә юнәлтү
~ войск гаскәрләрне күчерү
отдание чести честь бирү
отдача *ж* 1. кайтару 2. бирү 3. сугу, бәрү
~ приказа боерык бирү
отдел *м* бүлек
~ кадров кадрлар бүлеге
отделение *с* 1. отделение 2. бүлек, бүлекчә, бүлемтек
откат *м* артка чигү (орудиенең аткаӊнан соң артка чигенүе)
отклонение *с* авышу, тайпылу, тайпылыш
~ стрелки укның тайпылышы
вероятное ~ ихтимал тайпылыш
откомандировать *(икенче урынга)* күчерергә, җибәрергә
отлив *м* су чигенеше *(океан һәм ачык диңгез суларының күтәрелештән соң яңадан кимүе)*
отлучка *ж* китү, китеп тору
самовольная ~ рөхсәтсез китү
отметка *ж* 1. билгеләү, тамгалау, тамга салу 2. билге, тамга
отпуск *м* отпуск, ял
быть в ~е ялда булырга
внеочередной ~ чираттан тыш ял
краткосрочный ~ кыска вакытлы ял
~ по болезни авыру сәбәпле ял
очередной ~ чираттагы ял
отравление *с* агулану, агулау
отравляющ//ий агулаучы, агулы
~ие вещества агулы матдәләр, агулаучы матдәләр
отражатель *м* кайтаргыч *(яктылык, җылылык нурларын, электромагнит дулкыннарны кайтара торган җайланма)*
отражать кайтарырга, кире кайтарырга, кире кагарга
~ атаку һөҗүмне кире кагарга
отражение *с* 1. кайтару, кире кайтару, кире кагу 2. кайтару, чагылдыру, чагылыш
отрыв *м* 1. артта калу, аерылу 2. аеру 3. күтәрелеп китү
отряд *м* отряд
передовой ~ алдынгы отряд
поисковый ~ эзләнү отряды
сторожевой ~ каравыл отряды
отсек *м* отсек, бүлек *(корабтагы, самолеттагы һ.б. бүлмә)*
моторный ~ мотор отсегы

отселение *с* күчереп утырту, күчереп урнаштыру
отсечь кисеп алырга, аерырга
~ **пехоту от танков** пехотаны танклардан аерырга
отсрочка призыва хәрби хезмәткә чакыруны кичектерү
отставить! *(команда)* отставить! *(бирелгән команданы (боерыкны) «үтәмәскә» мәгънәсендә)*
отставк//а *ж* отставка *(бөтенләйгә хезмәттән чыгу)*
выходить в ~у отставкага чыгарга
отставной отставкадагы
отступательный чигенү ...ы, е
отступление *с* чигенү
оттеснять кысрыкларга, кысрыклап чыгарырга
оттянуть курок курокны тартып куярга
отход *м* чигенү, чигү
беспорядочный ~ тәртипсез чигенү
планомерный ~ планлы чигенү
преднамеренный ~ максатчан чигенү
отчет *м* хисап, отчет
отчислить (исемлектән) чыгарырга
офицер *м* офицер
~ **запаса** запастагы офицер
младший ~ кече офицер
старший ~ өлкән офицер
штабной ~ штаб офицеры
охват м колач, колачлау
охрана *ж* 1. саклау, каравыллау 2. сак, каравыл, сакчылар
охранение *с* сакчы төркем
оценка *ж* бәяләү, бәя бирү
очаг *м* учак
очередность *ж* чират, чиратлылык
соблюдать ~ чират сакларга
очередь *ж* 1. чират 2. очередь *(коралдан ату турында)*
пулеметная ~ пулемет очереде
очистка *ж* 1. чистарту, сафландыру, тоныкландыру 2. бушату *(чыгып китү)*
очки *мн.* күзлек
защитные ~ саклавыч күзлек
полетные ~ очучы күзлеге
ощущение *с* сизү, тою, тойгы, хис

П

павший в бою сугышта һәлак булган, ятып калган
падение *с* төшү, егылу, түбәнәю, кимү, азаю
паек *м* паек *(билгеле бер срокка һәм билгеле күләмдә бирелә торган азык-төлек)*
неприкосновенный ~ кагылгысыз паек
сухой ~ коры паек *(кайнар аш урынына продуктлата бирелә торган паек)*
пайол *м* пайол *(диңгез йөк судносы трюмындагы агач түшәмә)*
пакет *м* 1. пакет, хат 2. пакет, капчык
индивидуальный ~ шәхси пакет *(шәхси файдаланудагы яра бәйләвеч материаллар җыелмасы)*
индивидуальный противохимический ~ шәхси химик саклану пакеты
секретный ~ яшерен пакет
пакля *ж* сүс, чүбек
пакт *м* пакт *(халыкара килешү)*
~ **о взаимной помощи** үзара ярдәмләшү пакты
~ **о ненападении** һөҗүм итешмәү турында пакт
палатк//а *ж* чатыр, палатка *(су үткәрми торган тукымадан яки тиредән, җиргә утыртылган казыкларга тарттырып ясалган, вакытлыча ышыклану өчен хезмәт итә торган корылма)*
разбить ~у чатыр корырга
палач *м* палач, җәллад *(үлемгә хөкем ителгәннәрне җәзаны җиткерүче кеше)*
палаш *м* палаш *(төз, озын кылыч; атлы гаскәр коралы булган)*
палить (еш-еш) атарга *(туптан, мылтыктан)*
палица *ж* чукмар, гөрзи *(борынгы сугыш коралы; бер башы йомры кыска авыр күсәк)*
палуба *ж* палуба
верхняя ~ өске палуба
шлюпочная ~ шлюпка палубасы
панель *ж* панель *(нинди дә булса җайланманың, агрегатның яки приборның детальләр, җыелма элементлар монтажлана торган өлеше)*
паник//а *ж* паника, хәвеф, каушау, куркуга төшү
впасть в ~у паникага бирелергә
охваченный ~ой паникага бирелгән
поднимать ~у паника күтәрергә
сеять ~у паника таратырга
паникер *м* паникер, паника таратучы
паникерствовать паникага бирелергә, куркуга төшәргә

панический 1. паникалы 2. паникага бирелүчән, паникачыл, куркак
панорама *ж* панорама *(артиллериядә кулланыла торган оптик прибор)*
пантометр *м* пантометр *(якынча түгәллек белән топографик план төшерүдә кулланыла торган почмак үлчәгеч инструмент)*
панцирь *м* 1. *тар.* көбә, панцирь *(бик күп вак металл боҗраларны бер-берсенә кертеп ясалган хәрби күлмәк)* 2. панцирь *(хәрби корабларда, поездларда)*
папаха *ж* папаха
пар *м* пар, бу
быть под ~ами кузгалып китәргә торган *(пароход, паровоз турында)*
на всех ~ах җан-фәрманга, бөтен көчкә, җилдереп
парабеллум *м* парабеллум *(автомат принцибында ата торган пистолетларның бер төре)*
параван *м* параван *(диңгездә баручы корабларның корпусларын якорьлы миналарга бәрелүдән саклаучы трал тибындагы җайланма)*
парад *м* парад *(хәрби көчләрнең тантаналы рәвештә карилуы)*
военно-морской ~ хәрби-диңгез парады
воздушный ~ һава парады
~ Победы Җиңү парады
принимать ~ парад кабул итәргә
парализовать *перен.* көчсезләндерергә, зәгыйфьләндерергә
~ силы противника дошман көчләрен зәгыйфьләндерергә
параллакс *м* параллакс *(күзәтүченең күзе икенче ноктага күчү нәтиҗәсендә нәрсәнеңдер торышының күренмә күчеше)*
парашют *м* парашют *(очкыч аппаратлардан җир өстенә сикереп төшкәндә, әйберләр яки космик аппаратның төшерелә торган өлешен һ.б. төшергәндә төшү тизлеген киметү җайланмасы)*
парашютировать иң акрын тизлектә очарга *(самолет, аэростат турында)*
парашютист *м* парашютчы
парировать кайтарып сугарга *(кылыч сугышында каршы якның сугуына җавап кайтару)*
паритет *м* паритет *(кораллы көчләр һәм коралдар өлкәсендә тигез, бертөрле дәрәҗә, тигез хокуклылык принцибы)*
парламентер *м* парламентер *(үзара сугышучы ике якның берсеннән икенчесенә сөйләшүләр алып бару өчен җибәрелгән рәсми кеше)*
парламентерство *с* парламентерлык, парламентер вазифасы
пароль *м* пароль, ым *(каравылда торган үз кешеләрне таныту өчен әйтелә торган яшерен сүз)*
паром *м* паром *(кешеләрне, йөкләрне, техниканы зур елгалар аша кичерү өчен бер ярдан икенче ярга йөри торган зур палубалы махсус судно яки сал)*
железнодорожный ~ тимер юл паромы
~ная переправа паромлы кичү
переправляться на ~е паром белән кичәргә
паромщик *м* паромчы
партизан *м* партизан *(илгә басып кергән дошман тылында үзлегеннән оешып, мөстәкыйль хәрәкәт итә торган хәрби отряд сугышчысы, халык сугышында катнашучы)*
партия *ж* партия *(беришле әйберләрнең яки бер категориягә кергән кешеләрнең беркадәр сандагы төркеме)*
~ боеприпасов бер партия сугыш кирәк-яраклары
~ раненых бер партия яралылар
пасть 1. һәлак булырга, ятып калырга, корбан булырга 2. җиңелергә, бирелергә, бәреп төшерелергә
~ смертью храбрых батырларча һәлак булырга
патрон *м* патрон *(ату коралларының һәм кече калибрлы тупларның сугыш кирәк-ярагы)*
холостой ~ пулясыз патрон
патронник *м* патрон оясы *(ату коралларында патрон кертелә торган урын)*
патронташ *м* патронташ *(патрон йөртү өчен патрон оялары булган махсус сумка яки тасма)*
патрулировать патрульлек итәргә, патруль торырга
патруль *м* патруль *(дошманны күзәтү, аерым бер районны саклау өчен билгеләнгән хәрби хезмәткәрләр төркеме яки кораб, самолет һ.б.)*
патрульный 1. патруль *(патруль торучы кеше)* 2. патруль ...ы, е
педаль *ж* педаль, тәбәлдерек
пеленг *м* пеленг *(1. тавыш яки якты-*

лык килгән юнәлеш белән компас угы юнәлеше арасындагы почмак 2. махсус аппаратлар белән бик ерактан тыңлана торган тавыш сигналы)
пеленгатор *м* пеленгатор *(1. пеленг билгеләү приборы 2. пеленг белгече)*
пеленгация *ж* пеленгация, пеленглау
перебазировать(ся) яңа урынга күчерергә (күчергә)
перебежчик *м* дошман ягына качып чыккан кеше
перебрасывать (икенче урынга) күчерергә, ташларга
перевал *м* уткел, тау сырты аша үтә торган юл
перевес *м* өстенлек, артыклык
обеспечивать ~ дошманнан өстенлекне тәэмин итәргә
численный ~ сан ягыннан өстенлек
перевод *м* 1. *(хезмәт буенча)* күчерү 2. тәрҗемә
переводчик *м* 1. *техн.* күчергеч 2. тәрҗемәче, тылмач
перевооружать янадан коралландырырга, коралларны яңартырга
переворот *м* 1. әйләнү, каплану 2. переворот, кискен борылыш
перевязка *ж* (яраны) бәйләү
перевязочный бәйләү ...ы, е; бәйләвеч
~ **материал** бәйләвеч материал
~ **пункт** яра бәйләү пункты
переговоры сөйләшүләр, фикер алышулар
~ **о перемирии** килешү турында сөйләшүләр
перегрузка *ж* артык йөкләнеш
перегруппировка *ж* яңадан төркемләү
передатчик *м* тапшыргыч
передвижение *с* күчү, күчеп утыру
передышка *ж* вакытлы тынлык *(сугыш хәрәкәтләренең вакытлыча тукталып торуы)*
переключатель *м* күчергеч
перекрестный төрле яктан, як-яктан
~ **огонь** як-яктан утка тоту
перекресток *м* чат, юл чаты, урам чаты
перекрыть ябарга, бүләргә, буарга
~ **движение** хәрәкәтне ябарга
перелет *м* 1. очыш 2. (цельдән) уздыру
ремонт *м* ремонт, төзәтү *(1. зарарланган, тузган, ватылган әйберләрне төзәтү 2. гаскәрдә сафтан чыккан атларны алыштыру, тулыландыру. Шуның өчен билгеләнгән атлар)*
капитальный ~ капиталь ремонт
~ **часов** сәгать төзәтү
текущий ~ агымдагы ремонт
ремонтировать ремонтларга, төзәтергә, ремонт ясарга
ремонтн//ый ремонт ...ы, е; ремонтлау ...ы, е
инженерная ~ **ая рота** инженерлык ремонт ротасы
ремонтер *м иск.* ремонтер *(патша армиясендә хәрби частьлар өчен атлар сатып алу белән шөгыльләнүче офицер)*
реорганизовать үзгәртеп корырга
репер *м*: **артиллерийский** ~ артиллерия реперы *(орудиедән атып төзәгечне дөресләү өчен кулланыла торган ярдәмче нокта. Әлеге ноктадан ут цельгә күчерелә)*
ретирада *ж* ретирада, чигенү
ретироваться чигенергә, качарга
ретрансляция *ж* ретрансляция *(тапшыруларны көчәйтү һәм ераклыкка дөрес җиткерү өчен көчәйтеп яңадан тапшыру)*
ретраншемент *м иск.* ретраншемент *(оборонада торучыларның төп пози-*

циясеннән артта урнашкан ныгытма)
решение *с* 1. карар, хөкем 2. карар, нәтиҗә 3. чишү, хәл итү, карар чыгару
принимать ~ карар итәргә
формулировать ~ карарны рәвешкә китерергә
рикошет *м* рикошет *(очып килгән әйбернең нинди дә булса өслеккә бәрелгәннән соң почмак ясап очуы)*
ринуться ябырылырга, атылырга, ташланырга
~ **в бой** сугышка ташланырга
риск *м* 1. хәтәр, хәвеф-хәтәр 2. тәвәккәлләргә
на свой страх и ~ тәвәккәлләп
подвергать себя ~**у** үзеңне куркыныч астына куярга
рисковать 1. *(үзеңне, тормышны)* куркыныч астына куярга 2.тәвәккәлләргә
ров *м* озын чокыр, канау
противотанковый ~ танкка каршы чокыр
род *м* төр *(асыллары, кулланыш максатлары бердәй булган нәрсәләрнең башкалардан аерылып торган төркемнәре)*
~ **авиации** авиация төре
~ **войск** гаскәр төре
ромб *м* ромб *(1943 елда погоннар кертелгәнче, Совет Армиясе югары команда составының аеру билгесе)*
рота *ж* рота *(батальон составындагы гаскәри берәмлек)*
ротмистр *м* ротмистр *(элекке Россиядә атлы гаскәрдәге офицер дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәдәге кеше. Пехотадагы капитан дәрәҗәсенә туры килә)*
ротор *м* ротор *(турбина, электр двигателе һ.б.ның әйләнә торган өлеше, валы)*
ртуть *ж* терекөмеш
гремучая ~ янгыравык терекөмеш
рубеж *м* рубеж, сызык
оборонительный ~ оборона сызыгы
рубка *ж* рубка *(корабның өске палубасында идарә постлары урнашкан корылма)*
рубцеваться бетәшергә, төзәлергә
рудерпис *м* рудерпис *(суднодагы руль рамының вертикаль өлеше)*
рукав *м* 1. елга тармагы 2. жинсә, эчәк *(насоста)*
руки вверх! *(команда)* кулларыңны күтәр!
руководитель *м* җитәкче
руководство *с* 1. җитәкчелек, җитәкчелек итү 2. кулланма 3. җитәкчелек *(җитәкче кешеләр)*
~ **полетами** очышлар белән җитәкчелек итү
рукопашн//ый 1. кул ...ы 2. *в знач. сущ.*
~**ая** *ж* кул сугышы, якыннан торып сугышу *(мәс. штыкка штык килеп сугышу)*
~ **ый бой** кул сугышы
рукоприкладство *с* кул салу *(кыйнау)*
рукоятка *ж* тотка, сап
~ **кинжала** хәнҗәр сабы
рулевой *м* рулевой *(корабта)*; койрыкчы *(көймәдә)*
рулить 1. идарә итәргә, рульдә утырырга 2. борырга *(машинаны, очкычны һ.б.)*
румб *м* румб *(компас түгәрәгендә горизонтның 1/32 өлешенә тигез бүлем)*
румпель *м* румпель *(судноның рулен бору рычагы)*
ручн//ой кул ...ы
~**ая граната** кул гранатасы
~**ая кладь** кул йөге
~**ой пулемет** кул пулеметы
рушить жимерергә, ишәргә, кыйратырга
~ **стены** стена жимерергә
рынд//а *ж* рында, чаң сугу
~**у бить** рында кагарга *(җилкәнле судноларда төш вакыты җитүен белдереп чаң сугу)*
рыцарь *м* рыцарь *(1. тар. Көнбатыш Европада феодализм чорында атлы гаскәрдә хезмәт итүче феодал 2. күч. каһарман, фидакарь хезмәт итүче, егётлек кылучы)*
рычаг *м* рычаг *(1. таяну ноктасы тирәсендә борыла ала һәм аз көч куеп авыр нәрсәне күтәрү өчен хезмәт итә торган җайланма 2. идарә итү тоткасы)*
ряд *м* рәт, саф
в ~**ы стройся!** *(команда)* сафка тезел!
~**ы вздвой!** *(команда)* сафларны икеләт!
рядовой *м* рядовой *(командирлар составында булмаган, гади хәрби хезмәткәр)*
ряж *м* ряж *(агач бура итеп ясалган*

һәм таш тутырылган корылма. Зур тизлектә агучы елгалар аша күперләр салганда терәк итеп кулланыла)

С

сабельный кылыч ...ы, е; кылыч белән; кылычлы

~ **удар** кылыч белән чабу

сабля *ж* кылыч *(кешене чабып яки чәнчеп үтерү өчен хезмәт итә торган, бер йөзе генә үткен, кәкре озын корыч пластинадан гыйбарәт корал. Икенче бөтендөнья сугышы азагына кадәр гаскәрләрдә сугыш коралы булып торган, хәзер — спорт коралы)*

сажать утыртырга, җиргә төшерергә

~ **самолет** очкычны җиргә төшерергә

салют *м* салют *(рәсми сәламләүнең яки хөрмәтләүнең бер төре, мәс., төрле ут коралыннан атып; кылыч, мылтык, флаг күтәреп һ.б.)*

артиллерийский ~ артиллерия салюты

произвести ~ салют бирергә

~ **наций** милләтләр салюты *(дәүләт һәм хөкүмәт башлыклары, шулай ук чит ил хәрби кораблары хөрмәтенә, алар рәсми визит белән килгәндә бирелә)*

салютовать салют бирергә, сәламләргә

самовзрыватель *м* үзлегеннән шартлаткыч

самовозгореться үзлегеннән кабынып китәргә, үзеннән-үзе кабынырга

самовольн//ый рөхсәтсез, үз белдеге белән

~ **ая отлучка** *(из расположения части)* рөхсәтсез китү

самозарядн//ый үзлегеннән корылмалы

~ **ая винтовка** үзлегеннән корылмалы винтовка

самозащит//а *ж* үз-үзенне саклау, саклану

инстинкт ~ **ы** үз-үзенне саклау инстинкты

самолет *м* очкыч, самолет

выравнивать ~ очкычны турайтырга

сбивать ~ очкычны бәреп төшерергә

управлять ~ **ом** очкыч белән идарә итәргә

беспилотный ~ пилотсыз очкыч

ведущий ~ әйдәп баручы очкыч

высокоскоростной ~ зур тизлекле очкыч

высотный ~ зур биеклектә оча торган очкыч

маневренный ~ маневрлы очкыч

неопознанный ~ танылмаган очкыч

пилотируемый ~ пилотлы очкыч

поисковый ~ эзләнү очкычы

противолодочный ~ көймәләргә каршы очкыч

разведывательный ~ разведка очкычы

реактивный ~ реактив очкыч

рейсовый ~ рейс очкычы

санитарный ~ санитария очкычы

серийный ~ серия белән чыгарылган очкыч, серияле очкыч

скоростной ~ зур тизлекле очкыч

спасательный ~ коткару очкычы

транспортно-десантный ~ транспорт-десант очкычы

учебный ~ өйрәнү очкычы

~ **-нарушитель** *м* чик бозучы очкыч

~ **-ракетоносец** *м* ракета йөртүче очкыч

~ **-торпедоносец** *м* торпеда йөртүче очкыч

самолетн//ый очкыч ...ы, е

~ **ая разведка** очкыч разведкасы

~ **ое шасси** очкыч шассие

самолетовождение *с* очкыч йөртү

самолетостроение *с* очкыч ясау, очкыч төзү

самонаведение *с* үзлегеннән төзәү (төбәү)

самооборона *ж* үзоборона, үз-үзеңне саклау *(дошман һөҗүменнән)*

самоокапывание *с* үзеңә окоп казу

самописец *м* яздыргыч *(үзе яза торган җайланма)*

~ **давления** басым яздыргыч

саморазряд *м* үзлегеннән бушану *(мәс., аккумуляторның)*

саморегуляция *ж* үзлегеннән көйләнү

самосмаз *м* үзлегеннән майлану

самоходный үзйөрешле

санитар *м* санитар *(авыруларны, яралыларны карау, дәвалау, йортып җыештыру һ.б. эшләрне башкаручы кече медицина хезмәткәре)*

санитарн//ый санитария ...ы, е; санитар

~ **ая часть** санитария часте, санитар часть

~ **ый поезд** санитария поезды, санитар поезд

сап//а *ж* сапа *(траншеянең бер төре— дошман урнашкан урынга акрынлап*

һәм сиздермәстән якынлашу өчен ясалган йөрү юлы)

тихой ~ой астыртынлык белән, искәрмәстән, сиздермәстән

сапер *м* сапер *(төзү-кору һ.б. эшләр белгече; шундый частьтагы хәрби хезмәткәр)*

~ное дело саперлык эше

~ный батальон саперлар батальоны

сбивать атып төшерергә, бәреп төшерергә

сближаться, сближение якын килергә, якынаерга, якынлашырга

сбор *м* сбор *(1. уставта каралган сигнал буенча подразделениеләрнең, частьларның билгеләнгән бер районда (пунктта) туплануы 2. кыска сроклы хәрби өйрәнү хезмәте 3. корабларда хезмәт итүчеләр составын сафка тезү (зур сбор һәм кече сбор) 4. сафлар белән идарә итү сигналы)*

сбрасыватель *м* ташлагыч, ыргыткыч

автоматический ~ автоматик ташлагыч

сбрасывать 1. ташларга, төшереп җибәрергә, ыргытырга 2. алып ташларга 3. салырга, салып ташларга, коярга 4. алып ташларга, бәреп төшерергә

~ давление басымны төшерергә

~ десант десант төшерергә

свалить ташларга, ыргытырга, аударырга, төшереп җибәрергә

сведения белешмә, хәбәрләр, мәгълүмат(лар)

по полученным ~м алынган хәбәрләргә караганда

добывать ~ мәгълүмат табарга

доставлять ~ мәгълүмат китерергә (тапшырырга)

сопоставлять ~ мәгълүматларны чагыштырырга

достоверные ~ ышанычлы мәгълүмат

разведывательные ~ разведка мәгълүматы

свернуть 1. кысарга, тарайтырга, киметергә 2. читкә борылырга

~ голову 1. муенын борырга, муенын сындырырга 2. *куч.* башына җитәргә, дөмектерергә

~ с дороги юлдан читкә борылырга

~ фронт фронтны тарайтырга

сверну//ться 1. оерга, оешырга 2. *куч.* кысылырга, тараерга, кимергә

кровь ~лась кан оешты

фронт ~лся фронт тарайды

сверхзвуковой тавыштан тизрәк очучы

~ самолет тавыштан тизрәк очучы очкыч

сверхсрочнослужащий *м* сроктан тыш хезмәт итүче *(мәҗбүри хезмәт срогы тулганнан соң үз теләге белән армиядә калган гаскәри)*

сверхсрочн//ый 1. сроктан тыш 2. бик ашыгыч, үтә ашыгыч

~ая военная служба сроктан тыш хәрби хезмәт

~ое задание үтә ашыгыч задание

светомаскировка *ж* яктылыкны маскировкалау, яктылыкны яшерү

светонепроницаемый яктылык үткәрми торган

светосила *ж* яктылык көче

светофильтр *м* яктылык фильтры *(төрле төстәге яктылыктан үз төсендәге яктылыкны гына аерып үткәрә торган пыяла, пленка яки сыеклык)*

свеч//а *ж* 1. шәм 2. *техн.* шәм, кабызгыч 3. шәм *(очкычның текә күтәрелүе)* 4. шәм *(яктылык көче берәмлеге)*

запальная ~а кабызгыч шәм

самолет сделал ~у очкыч шәмдәй күтәрелде

электрическая лампочка в сто ~ей йөз шәмлек электр лампасы

свидетельство *с* таныклык

приписное ~ теркәлү турында таныклык, теркәлү таныклыгы

сводка *ж* сводка, мәгълүмат *(агымдагы мәгълүматны туплап, тәртипкә салып күрсәтә торган язу; белешмә)*

метеорологическая ~ метеорологик мәгълүмат

~ погоды һава торышы турында мәгълүмат

~ по связи элемтә буенча сводка

сводный җыелма

~ батальон җыелма батальон

свойство *с* үзлек, сыйфат, үзенчәлек

боевое ~ сугышчан үзлек

связист *м* элемтәче

связной *м* элемтәче *(сугыш, өйрәнүләр, маневрлар вакытында донесениеләр китерү, боерыклар тапшыру өчен командир тарафыннан билгеләнгән хәрби хезмәткәр)*

связь *ж* элемтә

восстанавливать ~ элемтәне торгызырга

обеспечивать ~ элемтә белән тәэмин итәргә
поддерживать ~ элемтә тотарга
устанавливать ~ элемтә урнаштырырга
бесперебойная ~ өзлексез элемтә
двусторонняя ~ ике яклы элемтә
звуковая ~ тавыш элемтәсе
зрительная ~ күз элемтәсе
многоканальная ~ күп каналлы элемтә
непосредственная ~ турыдан-туры элемтә
проводная ~ чыбыклы элемтә
радиотелеграфная ~ радиотелеграф элемтәсе
радиотелефонная ~ радиотелефон элемтәсе
фельдъегерская ~ фельдъегер аша элемтә

сгореть янарга, янып бетәргә
~ **дотла** янып көл булырга

сгубить һәлак итәргә, харап итәргә, башына җитәргә

сдавать 1. бирергә, *(дошман ягында)* калдырырга 2. тапшырырга, бирергә

сдаваться 1. бирелергә 2. күнергә, бирешергә
~ **в плен** әсирлеккә бирелергә

сдвоенн//ый 1. куш, икешәрле 2. ике катлы
~**ые ряды** куш рәтләр, икешәрле рәтләр

сдвоить 1. ике рәткә тезәргә, икешәрләп тезәргә 2. ике катларга, икешәрләргә

сдержать 1. туктатырга 2. үтәргә
~ **клятву** антны үтәргә
~ **натиск противника** дошманның һөҗүмен туктатырга

седловина *ж* билдәү, сыртлавык *(ике тау түбәсе арасындагы бил.ләнеп торган урын)*

секира *ж* айбалта *(озын саплы балта сыман борынгы салкын корал)*

секрет *м* секрет *(алгы позициядә дошман күрмәслек урында яшеренеп күзәтчелек итүче хәрби пост)*

секретность *ж* яшеренлек

секретн//ый яшерен
~ **документ** яшерен документ
совершенно ~**о** үтә яшерен

секстант *м* секстант *(астрономик һәм геодезик күзәтүләр вакытында почмак үлчәү коралы)*

сектор *м* сектор *(берәр мәйданның радиаль сызыклар белән чикләнгән өлеше)*
~ **видимости** күренү секторы
~ **наблюдения** күзәтү секторы
~ **обстрела** ату секторы
~ **ПВО** һава һөҗүменә каршы оборона (ПВО) секторы

секунд-майор *м* секунд-майор *(XVIII—XIX гасырларда рус армиясендә кече штаб офицеры чины)*

сераскер *м* сәргаскәр *(солтан Төркиясендә — баш командан; XIX гасырда — хәрби министр)*

сервомеханизм *м* сервомеханизм *(хәрәкәтнең механик энергиясен арттыра торган җайланма)*

сердечник *м* кендек, үзәк
~ **пули** пуляның үзәге
~ **снаряда** снарядның үзәге
~ **электромагнита** электромагнит кендеге

сержант *м* сержант *(кече команда составы вәкилләренә бирелә торган исем, дәрәҗә. Шул исемне алган кеше)*
младший ~ кече сержант
старший ~ өлкән сержант

сестра *ж*: ~ **милосердия** шәфкать туташы

сетка *ж* челтәр
градусная ~ градуслар челтәре
маскировочная ~ маскировка челтәре
мелкоячеистая ~ вак күзәнәкле челтәр
проволочная ~ тимерчыбык челтәр
~ **оптического прицела** оптик төзәгеч челтәре

сеть *ж* челтәр
~ **оповещения** хәбәр челтәре
~ **связи** элемтә челтәре
дорожная ~ юллар челтәре
железнодорожная ~ тимер юллар челтәре

сечение *с* киселеш, кисем
поперечное ~ аркылы кисем

сжатие *с* кысылу *(көч тәэсирендә җисемнең буе кыскару яки күләме кечерәю)*

сжат//ый 1. кысылган, тыгызландырылган 2. кыска, кыскартылган
~**ый воздух** кысылган һава
в ~**ые сроки** кыска вакытта

сигнал *м* сигнал *(хәбәр тапшыру өчен кулланыла торган шартлы элемтә чарасы)*
передавать ~ сигнал тапшырырга
подавать ~ сигнал бирергә

~ **атаки** һөҗүм сигналы
~ **бедствия** бәла-каза (һәлакәт) сигналы
~ **взаимодействия** үзара бәйләнеш сигналы
~ **воздушной тревоги** һава тревогасы сигналы
~ **оповещения** хәбәр итү сигналы
~ **опознавания** танышу сигналы
~ **целеуказания** цель күрсәтү сигналы
условный ~ шартлы сигнал
флажный ~ флаг сигналы
сигнализатор *м* сигнализатор *(сигнал бирү җайланмасы, аппараты; шуның сигнал тапшыра торган кисәге)*
сигнализация *ж* 1. сигнал бирү 2. сигнализация 3. сигналлар системасы
сигнализировать 1. сигнал бирергә 2. *күч.* алдан искәртергә, кисәтеп куярга, хәбәр җиткерергә
сигнальщик *м* сигналчы, сигнал бирүче
сиденье *с* утыргыч
катапультируемое ~ катапульталы утыргыч *(очкыч аппаратлардан очучыны читкә атып чыгару өчен автомат коткару җайланмасы)*
сикурс *м* сикурс *(1. ярдәм; ярдәмгә җибәрелгән гаскәр 2. һөҗүм; тетрәү)*
сил//а *ж* 1. көч, хәл, дәрман 2. гамәл
вооруженные ~**ы** коралды көчләр
выбиться из ~ хәлдән таярга
применить ~**у** көч кулланырга
~**а тока** ток көче
закон вступил в ~**у** закон гамәлгә керде
движущая ~**а** этәрү көче
убойная ~ **а** үтерү көче
ударная ~**а** бәрү көче
уравновешивающая ~**а** тигезләүче көч
центробежная ~**а** үзәктән куу көче
центростремительная ~**а** үзәккә омтылу көче
электродвижущая ~**а** электр йөртү көче (вольтлар белән үлчәнә)
сирена *ж* сирена *(көчле тавышлы сузынкы сигнал бирә торган аппарат, җайланма; кискен һәм улауга охшаш сузынкы тавыш)*
система *ж* система
~ **автоматического регулирования** автоматик көйләү системасы
~ **автоматического управления** автомат идарә итү системасы
~ **впрыска топлива** ягулык бөркү системасы
~ **герметизации кабины** кабинаны герметиклаштыру системасы
~ **заправки топлива** ягулык салу системасы
~ **зажигания** кабызу системасы
~ **координат** координатлар системасы
~ **ПВО** һава һөҗүменнән саклану системасы, ПВО системасы
~ **сопровождения (цели)** эзәрләү системасы, озата бару системасы
~ **стабилизации** тотрыкландыру системасы
~ **управления** идарә системасы
~ **управления огнем** ут белән идарә итү системасы
пожарная ~ янгын сүндерү системасы
сточная ~ *мор.* су агызу системасы
скампавея *ж* скампавея *(галера флотының тиз йөрешле, ишкәкле хәрби судносы)*
сканер *м* сканер *(радиоизотоп диагностикасы приборы)*
сканирование *с* сканерлау
скат *м* сөзәклек
на ~**е холма** тау битендә
скатка *ж* 1. тәгәрәтеп төрү 2. скатка *(кулбаш аркылы асып йөртү өчен торба ясап төрелгән һәм башлары бәйләнгән шинель)*
скафандр *м* скафандр *(су астына төшкәндә, галәмгә очканда һ.б. очракта кия торган, сулау аппараты куеп эшләнгән махсус герметик кием)*
скачок *м* 1. сикерү, сикереш 2. кинәт үзгәрү, күтәрелү
~ **прицела** төзәгечнең сикерешe
скважина *ж* скважина *(җирне бораулап ясалган тирән, тар тишек)*
взрывная ~ шартлау скважинасы
сквозной үтәли, үтәдән-үтә
~**ая рана** үтәли яра
склад *м* склад *(әйбер саклый торган махсус урын, бина)*
складки местности җир тигезсезлекләре
склонение *с* авышу
магнитное ~ магнит авышуы *(географик һәм магнит меридианнары арасындагы почмак)*
сковывание *с (дошманны)* тоткарлап тору, тыеп тору

склянк//а *ж* 1. склянка *(диңгезчеләрдә: ярты сәгать вакыт)* 2. *мн.* ~ **и (часы)** склянка *(корабтагы ком сәгате)*
скомандовать команда бирергә
скомплектовать комплектларга, тупларга, оештырырга
сконструировать конструкцияләргә, төзергә
сконцентрировать тупларга, концентрацияләргә
~ **войска** гаскәр тупларга
скопировать копия алырга, күчермә алырга
скопление зур төркем, тупланма
скорбн//ый кайгылы, хәсрәтле, көенечле, сагышлы
~ **ая весть** кайгылы хәбәр
скоростной тиз йөри (оча, йөзә, хәрәкәт итә, ата) торган
скорость *ж* тизлек
заданная ~ билгеләнгән тизлек
звуковая ~ тавыш тизлеге
космическая ~ космик тизлек
начальная ~ башлангыч тизлек
сверхзвуковая ~ тавыштан югары тизлек
средняя ~ уртача тизлек
угловая ~ почмакча тизлек *(әйләнүче ноктаны әйләнү үзәгенә тоташтырган радиусның вакыт берәмлеге эчендә ясаган почмагы белән үлчәнә торган зурлык)*
скоротечный кыска вакытлы, җәһәт
скорректировать корректива ясарга, төзәтмә кертергә
скрытие *с* яшеренү, яшерү
скрытный яшертен, астыртын, мыштым
скученность *ж* оешып урнашу, оешлык
слава *ж* дан, шөһрәт, шан
боевая ~ сугышчан дан
славить данларга, дан жырларга, мактарга, мәдхия укырга
славиться дан тотарга, данлыклы булырга, атаклы булырга
славный данлыклы, данлы, атаклы, шөһрәтле
слагаемое *с* өлеш, кисәк
слаженность *ж* көйлелек, иплелек, килешенгәнлек, жайга салынганлык, оешканлык
след *м* эз
идти по ~ **ам** эздән барырга
слежени//е *с* эзәрләү, күзәтеп тору
станция ~ **я** күзәтү станциясе
слезоточивый яшь агызгыч
~ **газ** яшь агызгыч газ
слепой полет күрмичә очу *(приборлар буенча очу)*
слетанность экипажей экипажларның бергәләп очу осталыгы
слой *м* катлам, катлау, кат
ламинарный ~ ламинар катлам
распределительный ~ бүленеш катламы
служб//а *ж* хезмәт, хезмәт итү, служба
освободить от ~ **ы** хезмәттән азат итәргә
гарнизонная ~ **а** гарнизон хезмәте
караульная ~ **а** каравыл хезмәте
спасательная ~ **а** коткару хезмәте
срочная ~ **а** сроклы хезмәт
техническая ~ **а** техник хезмәт
служить хезмәт итәргә
~ **в армии** армиядә хезмәт итәргә
слух *м* 1. ишетү, ишетү сәләте 2. хәбәр, имеш-мимеш, гайбәт
слухач *м* слухач *(радио буенча сигналлар кабул итеп торучы)*
слушатель *м*: ~ **академии (курсов)** академиядә (курсларда) укучы
смазка *ж* 1. майлау, сылау 2. май *(майлау матдәсе)*
пушечная ~ туп мае
смелость *ж* кыюлык, батырлык, йөрәклелек
смельчак *м* кыю, батыр, йөрәкле
смена *ж* 1. алмаштыру, алыштыру 2. алмаш 3. смена
бодрствующая ~ уяу смена
~ **войск** гаскәрләр алышыну
сменять алмашырга, алышырга, алмаштырырга, алыштырырга
смертельн//ый 1. үлем ...ы, е; үлемгә китерә торган, үтергеч 2. *күч.* жимергеч 3. *күч.* бик нык
~ **ая борьба** һәлакәтле көрәш
~ **ая рана** үлем ярасы
смертник үлемгә хөкем ителгән кеше, үлемгә дучар кеше
смертоносн//ый үтерә торган, үтергеч, үлем китерүче, һәлак иткеч, һәлакәтле
~ **ое оружие** һәлакәтле корал
смесь *ж* катнашма
взрывчатая ~ шартлаучан катнашма
газовая ~ газ катнашмасы
горючая ~ янучан катнашма

дымовая ~ төтен катнашмасы
зажигательная ~ кабызгыч катнашма
топливовоздушная ~ ягулык-һава катнашмасы
смещение *с* күчү, тайпылу
смирно! *(команда)* үрә кат! *(төз басып хәрәкәтсез торырга боеручы хәрби команда)*
смотр *м* смотр, тикшерү *(тантаналы төстә уза торган рәсми тикшерү)*
инспекторский ~ инспектор тикшерүе
строевой ~ саф тикшерү
торжественный ~ тантаналы смотр
снабжение *с* тәэмин итү, тәэминат
~ **боеприпасами** сугыш яраклары белән тәэмин итү
бесперебойное ~ өзлексез тәэмин итү
вещевое ~ әйбер белән тәэмин итү
продовольственное ~ азык-төлек белән тәэмин итү
снайпер *м* снайпер, мөргән
снаряд *м* снаряд, туп ядрәсе
осколок ~**а** снаряд ярчыгы
бетонобойный ~ бетон ваткыч снаряд
бронебойно-зажигательный ~ броня ваткыч-яндыргыч снаряд
бронебойный ~ броня ваткыч снаряд
зажигательный ~ яндыргыч снаряд
зенитный ~ зенит снаряды
кумулятивный ~ кумулятив снаряд
неразорвавшийся ~ шартламаган снаряд
осветительный ~ яктырткыч снаряд
осколочный ~ ярчыклы снаряд
противотанковый ~ танкка каршы снаряд
трассирующий ~ яктыртып очучы снаряд
снаряжать кирәк-яраклар белән тәэмин итәргә, әзерләргә
снаряжение *с* кирәк-яраклар
снаст//ь *ж* 1. *собир.* җиһазлар, кирәк-яраклар, кораллар 2. *обычно мн.* ~**и** кораб баулары; канатлар
крепить ~**и** кораб бауларын ныгытырга, бәйләп куярга
снижаться түбәнәергә, түбән төшәргә
сняться с якоря! *(команда)* якорьны күтәр!
совещание *с* киңәшмә
согласовать 1. ярраштырырга, килештерергә, туры китерергә 2. килешергә, уртак фикергә килергә, хәл итәргә, сөйләшергә
соглашение *с* 1. үзара килешү 2. килешү документы
~ **о перемирии** вакытлы солых турында килешү
~ **о прекращении огня** атышны туктату турында килешү
содействие *с* ярдәм, булышлык
оказывать ~ ярдәм күрсәтергә, булышырга
содержание *с* 1. тоту, асрау 2. түләү
~ **под арестом** *(мәс., гауптвахтада)* ябып тоту
денежное ~ акчалата түләү, хезмәт хакы
соединение *с* 1. кушылу, берләшү 2. берләшмә
авиационное ~ авиация берләшмәсе
войсковое ~ гаскәри берләшмә
общевойсковое ~ гомумгаскәри берләшмә
ударное ~ удар берләшмә
сокращение вооруженных сил кораллы көчләрне кыскарту
солдат *м* солдат *(беренчел хәрби дәрәҗә; рядовой, ефрейтор дәрәҗәләрендәге хәрби хезмәткәрләрнең һәм армиядә хезмәт итәргә тиешле кешеләрнең категориясе)*
сомкнись! *(команда)* тыгызлан!
сомкнуться кысылырга, тыгызланырга
сообщение *с* 1. хәбәр, белдерү 2. аралашу, бәйләнеш, элемтә
сооружение *с* 1. кору, төзү, салу, торгызу, күтәрү 2. корылма 3. корылыш, төзелеш
~ **из подручных материалов** кул астындагы материаллардан төзелгән корылма
~ **стационарного типа** стационар типтагы корылма
долговременное ~ озак вакытлы корылма
инженерное ~ инженерлык корылмасы
маскировочное ~ маскировка корылмасы
фортификационное ~ фортификация корылмасы
соотношение *с* (үзара) бәйләнеш, нисбәт, (үзара) мөнәсәбәт
~ **сил** көчләр нисбәте
сопло *с* сопло *(газ, пар яки сыеклык*

агынтысына юнәлеш һәм тизләнеш бирү өчен җайланган көпшә, канал)
соприкосновение *с* тәрәлү, очрашу
~ **с противником** дошман белән очрашу
сопровождать озата барырга, озатып йөрергә
сопротивление *с* 1. каршы тору, каршылык күрсәтү, карышу 2. *техн.* каршылык
оказывать ~ каршылык күрсәтергә
подавлять ~ каршылыкны бастырырга
преодолевать ~ каршылыкны җиңеп чыгарга
организованное ~ оешкан төстә каршылык күрсәтү
сосредоточение *с* 1. туплау, җыю, туплану, җыелу 2. (бер ноктага) юнәлтү
~ **войск** көчләрне туплау
~ **огня** утны (бер ноктага) юнәлтү
состав *м* состав
боевой ~ сугышчан состав
железнодорожный ~ тимер юл составы
зажигательный ~ яндыргыч состав
инициирующий ~ кузгаткыч состав
кадровый ~ кадрлар составы
командный ~ команда составы
летный ~ очучылар составы
личный ~ хезмәт итүчеләр составы
обслуживающий ~ хезмәт күрсәтүче состав
переменный ~ алмашлы состав
постоянный ~ даими состав
рядовой ~ рядовой состав
технический ~ техник состав
численный ~ **войск** гаскәрнең санча составы
штатный ~ штаттагы состав
составитель *м* төзүче, әзерләүче
состояние *с* хәл, халәт
сотник *м* сотник *(патша армиясе составындагы казак гаскәрендә: кавалерия ротмистры белән тиң хәрби дәрәҗә. Шул дәрәҗәдәге офицер)*
сотня *ж* сотня *(патша армиясендә йөз кешедән торган гаскәри подразделение)*
сохранить 1. сакларга, саклап калырга 2. бозмаска
~ **верность присяге** антыңны бозмаска, антка тугрылык сакларга
сошник *м* төрән
союзник *м* союздаш, аркадаш
спалить 1. ут төртеп яндырырга, ут салырга 2. көйдерергә, көйдереп алырга
спардек *м* спардек *(корабларда өске корылма палубасы)*
спарить парларга, икешәрләп(парлап) куярга
спасательный коткару ...ы, е; коткаргыч ...
~ **круг** коткару бояфасы
~ **пояс** коткару поясы
специалист *м* белгеч
классный ~ класслы белгеч
младший ~ кече белгеч
специальность *ж* белгечлек
военно-учетная ~ хәрби-исәп белгечлеге
спешить(ся) аттан төшерергә (төшәргә) *(атлы гаскәр турында)*
спираль *ж* спираль *(бер нокта яки күчәр тирәли әйләнеп, зурая яки кечерәя барган, йомылмый торган әйләнәләр ясаучы кәкре сызык. Шундый формалы юнәлеш, эз, әйбер)*
крутая ~ текә спираль
нисходящая ~ кими баручы спираль
проволочн//ая ~ тимерчыбык спираль
~**ная пружина** спираль пружина
списаться (хезмәттән, экипаж составыннан) чыгарга, китәргә
~ **с корабля** кораб хезмәтеннән чыгарга
список *м* исемлек
~ **личного состава** хезмәт итүчеләр исемлеге
послужной ~ хәрби хезмәт кенәгәсе *(эшче яки хезмәткәрнең эш стажы, бүләкләнүе, макталуы һ.б. язып барыла торган документы)*
способность *ж* сәләт, мөмкинлек
пропускная ~ үткәрү сәләте
разрешающая ~ **микроскопа** микроскопның аеру сәләте
справиться 1. үтәргә, үти алырга, башкарырга, башкара алырга, башкарып чыгарга 2. җиңәргә, җиңеп чыгарга, җиңә алырга
справка *ж* белешмә, мәгълүмат
спуск *м* 1. ычкындыру 2. түбән таба юл, төшү юлы, төшү урыны
спусковой 1. ычкындыргыч 2. (аска) төшә торган
~ **механизм** ычкындыргыч механизм
спустить 1. ычкындырырга 2. төшерергә
~ **директиву** директива төшерергә

~ **курок** курокны ычкындырырга
спутник иярчен
~ **связи** элемтә иярчене
метеорологический ~ метеорологик иярчен
навигационный ~ навигация иярчене
разведывательный ~ разведка иярчене
сражаться сугышырга
сражени//е сугыш, зур сугыш
воздушное ~ **е** һава сугышы
морское ~ **е** дингез сугышы
оборонительное ~ **е** оборона сугышы
противовоздушное ~ **е** һава һөҗүменә каршы сугыш
решающее ~ **е** хәлиткеч сугыш
поле ~ **я** сугыш кыры
выиграть ~ **е** сугышта җинеп чыгарга
сразить (бәреп, атып) үтерергә
средств//о *с* чара
~ **а бактериологической войны** бактериологик сугыш чаралары
~ **а минирования и разминирования** миналау һәм миналардан арындыру чаралары
~ **а связи** элемтә чарасы
~ **а управления** идарә итү чаралары
~ **а химической защиты** химик саклану чарасы
имитационное ~ **о** имитация чарасы
индивидуальное ~ **о защиты** шәхси саклану чарасы
переправочное ~ **о** кичү чарасы
техническое ~ **о** техник чара
транспортное ~ **о** транспорт чарасы
штатное ~ **о** штаттагы чара
срок *м* срок, вакыт, чор, дәвер
~ **выслуги** хезмәт срогы
~ **службы в армии** армиядә хезмәт итү срогы
стабилизатор *м* стабилизатор
~ **напряжения** көчәнеш стабилизаторы
гироскопический ~ гироскопик стабилизатор
курсовой ~ курс стабилизаторы
стабилизация *ж* стабильләшү, стабильләштерү
ставка *ж* ставка *(1. гаскәр башлыгы яки аның штабы урнашкан урын 2. сугыш вакытында: иң югары командование органы)*
стажировка *ж* стажировка *(берәр эшкә керешү, билгеләнү алдыннан күнекмә, тәҗрибә алу өчен махсус сроклы сынау үтү)*
станина *ж* станина *(артиллерия тубы лафетының бер өлеше)*
~ **крестообразного лафета** тәресыман лафет станинасы
коробчатая ~ тартмасыман станина
становись! *(команда)* тезел!
станок *м* станок
~ **для наводки** төбәү станогы
~ **лафета** лафет станогы
орудийный ~ туп станогы
станция *ж* станция
метеорологическая ~ метеорологик станция
передвижная ~ күчмә станция
полевая почтовая ~ кыр почтасы станциясе
радиопеленгаторная ~ радиопеленг станциясе
радиотелеграфная ~ радиотелеграф станциясе
стапель *м* стапель *(судно корпусларын җыю һәм судноларны суга төшерү урыны)*
старшина *м* старшина *(кече команда составына бирелә торган иң югары хәрби дәрәҗә, шул дәрәҗәне алган кеше)*
ствол *м* көпшә, көбәк
стволь//ый көпшә ...ы, көбәк ...ы
~ **ая коробка ружья** мылтыкның көбәк тартмасы
стеклообогреватель *м* пыяла җылыткыч
стенобитн//ый стена ваткыч
~ **ые орудия** стена ваткыч кораллар
степень *ж* дәрәҗә
~ **заражения** агулану дәрәҗәсе
~ **поражения** зарарлану дәрәҗәсе
~ **радиоактивного заражения** радиоактив зарарлану дәрәҗәсе
~ **сжатия** кысылу дәрәҗәсе
стереотруба *ж* стереотруба *(оптик прибор)*
стой! *(команда)* тукта!
стойка *ж* торыш, басып тору
~ **смирно** үрә катып тору
строевая ~ сафта торыш
стой! Кто идет? *(команда)* Тукта! Кем килә?
столкновение *с* бәрелеш, бәрелү
вооруженное ~ кораллы бәрелеш

стопор *м* стопор *(механизмны туктата торган җайланма)*
сторона *ж* як, тараф
воюющая ~ сугышучы як
нападающая ~ һөҗүм итүче як
обороняющаяся ~ каршы торучы як
стоянка *ж* 1. туктау, туктап тору, тукталу 2. *(место)* (вакытлыча урнашкан) урын, туктап (тукталып тору) урыны, туктау (тукталу) урыны 3. *(для транспорта)* вакытлыча куеп тору урыны; тукталыш
авто~ автомобильлөр кую урыны, вакытлыча автомобильләр куеп тору урыны
стратег *м* стратег, стратегия белгече *(сугыш алып бару остасы)*
стратегический стратегия ...ы, е; стратегик
стратосфера *ж* стратосфера *(атмосфераның өске катламы)*
стрел//а *ж* ук
пустить ~у ук атарга
~а крана кран угы
стрелковый укчы(лар) ...ы, е; укчы ...
~ **полк** укчы полк
стреловидный уксыман
стрелок *м* укчы, атучы
стрельба *ж* ату, атыш
беспорядочная ~ тәртипсез атыш
~ **беглым огнем** тиз-тиз атыш
~ **залпами** залп белән ату
~ **короткими очередями** кыска чиратлар белән ату
~ **прямой наводкой** туры төзәп ату
~ **холостыми патронами** буш патроннар белән ату
стрельбище *с* ату урыны, атарга өйрәнү урыны
стрелян//ый 1. атып үтерелгән, атып төшерелгән 2. ут астында булган, сугыш күргән, сугышка кергән 3. атылган *(атуда файдаланылган)*
~ая гильза атылган гильза
~ый солдат ут астында булган солдат
стрелять атарга
стреляться 1. атылырга, үз-үзеңә атарга 2. *(дуэльдә)* атышырга
стремительность *ж* җитезлек, җәһәтлек, елгырлык
стрингер *м* стрингер *(судно яки очу аппаратының бөтен корпусы буйлап ныклы өрлек яки металл конструкция төсле итеп эшләнгән, аңа катылык һәм ныклык бирүче җайланма)*

строевым шагом марш! *(команда)* саф адымы белән марш!
строиться сафка тезелергә
стро//й *м* саф
встать в ~й сафка басарга
выбывать из ~я сафтан китәргә, сафтан чыгарга
выводить из ~я сафтан чыгарырга
выходить из ~я сафтан чыгарга
становиться в ~й сафка басарга
~й кильватера кильватер сафы *(кильватер агымында туры юнәлештә берсе артыннан берсе баручы кораблар сафы)*
двухшереножный ~й ике рәтле саф
одношереножный ~й бер рәтле саф
походный ~й поход сафы
развернутый ~й җәенке саф
разомкнутый ~й сирәк саф
расчлененный ~й бүлгәләнгән саф
сомкнутый ~й тыгыз саф
ступень *ж* 1. баскыч, басма 2. киртләч, чыгынты 3. *(үсеш)* этап, баскыч 4. дәрәҗә
ступить 1. атларга, аяк атларга 2. керергә, аяк басарга
стык *м (берәр нәрсәнең)* тоташкан (тоташтырылган, ялганган, беркетелгән) урыны (җире), ялганыш, ялганма, ялгау урыны
стычка *ж* бәрелеш, бәйләнешеп китү
стянуть 1. тартып бәйләргә, тарттырырга
2. җыярга, тупларга
~ **войска к переправе** гаскәрләрне кичү янына тупларга
суд *м* суд, хөкем
отдать под ~ судка бирергә
попасть под ~ судка тартылырга
привлечь к ~у хөкемгә тартырга
~ **чести** намус суды, намус хөкеме
военно-полевой ~ хәрби-кыр суды
военный ~ хәрби суд
показательный ~ күргәзмә суд
товарищеский ~ иптәшләр суды
судимость *ж* хөкемгә тартылган булу, хөкем ителгәнлек
снять ~ хөкем ителгәнлекне бетерергә *(гамәлдән чыгарырга)*
иметь ~ хөкемгә тартылган булырга
судно *с* судно *(пароход, кораб)*
~ **снабжения** тәэмин итү судносы
вспомогательное ~ ярдәмче судно
спасательное ~ коткару судносы
учебное ~ өйрәнү судносы

судоходство *с* 1. суднолар йөреше, суднолар йөрү 2. флот
каботажное ~ каботаж флоты
морское ~ дингез флоты
суматоха *ж* ыгы-зыгы, шау-шу, мәхшәр
сумка *ж* сумка, букча
патронная ~ патрон сумкасы
суточные *мн.* тәүлеклек акча *(мәс., командировкада булган көннәр өчен түләнә торган акча)*
сухопутн//ый коры җир ...ы, е
~ **ая армия** коры җир армиясе
~ **ые войска** коры җир гаскәрләре
сушилка *ж* киптерү урыны
сформировать төзергә, корырга, оештырырга, булдырырга
~ **полк** полк оештырырга
схватка *ж* бәрелеш, сугыш
рукопашная ~ кул сугышы *(атышусыз кара-каршы сугыш)*
схема *ж* схема
~ **взаимодействия** үзара ярдәм схемасы
сходни *мн.* басма *(көймәдән, корабтан ярга чыгу өчен куела торган басма)*
счетчик *м* счетчик, санагыч
~ **Гейгера-Мюллера** Гейгер-Мюллер счетчигы *(радиоактив кисәкчәләрне терки торган прибор)*
~ **координат** координатлар счетчигы
~ **оборотов** әйләнеш счетчигы
импульсный ~ импульслы счетчик
счисление *с* санау, исәпләү
~ **пути** юлны исәпләү
счислитель *м* санагыч, исәпләгеч
~ **ветра и параллакса** *арт.* җил һәм параллакс исәпләгече
сшибка *ж* бәрелеш, кечкенә сугыш
съемка *ж* (планга, картага) төшерү (төшереп алу), план алу; рәсем төшерү, рәсемгә төшү
глазомерная ~ күз чамасы белән төшерү
маршрутная ~ маршрут ысулы белән төшерү
топографическая ~ топографик рәсем (план)

Т

табель *м* табель
~ **вооружения части** частьның кораллар табеле
~ **донесений** белдерүләр табеле
~ **имущества** мөлкәт табеле
таблица *ж* таблица
~ **бомбометания** бомба ташлау таблицасы
такелаж *м* такелаж *(1. судноның аркан, бау кебек барлык җиһазлары 2. йөкне күтәрү һәм күчерү өчен кулланыла торган җайланмалар)*
тактик *м* тактик; тактика белгече
тактика *ж* тактика
общевойсковая ~ гомумгаскәри тактика
тактическ//ий тактик, тактика ...ы
~ **ая подготовка** тактик хәзерлек
~ **ие учения** тактик өйрәнүләр
тали *мор.* тали *(судноларда авыр әйберләрне күтәрү-төшерү өчен блоклар системасы)*
тангаж *м* тангаж *(очу аппаратының яки судноның очканда, йөзгәндә аркылы үзәккә карата авышуы; буйга кырынаю)*
танк *м* танк *(көчле кораллар белән җиһазланган һәм бөтенләй броняланган, чылбыр тәгәрмәчле, үзйөрешле сугыш машинасы, сәгатькә 70 км тизлек белән хәрәкәт итә ала)*
воздушно-десантный ~ һава десанты танкы
головной ~ алдан баручы танк
кочующий ~ күчмә танк
окопанный ~ казып урнаштырылган танк
плавающий ~ йөзә торган танк
сверхтяжелый ~ бик авыр танк
средний ~ уртача танк
танкер *м* танкер *(сыекчалар ташый торган судно)*
танкетка *ж* танкетка *(тиз йөрешле кечкенә танк)*
танкист *м* танкист, танкчы *(танк гаскәрләрендә хезмәт итүче кеше; танк экипажы әгъзасы)*
танк-мостоукладчик *м* күпер салучы танк *(күпер конструкциясен транспортлау, аны елга, чокыр кебек тоткарлыкларга урнаштыру һәм кире җыеп алу өчен билгеләнгән махсус танк)*
танков//ый танк(лар) ...ы, е
~ **ая атака** танк атакасы
~ **ые войска** танк гаскәрләре
танкодоступный танк үтә алырлык
танкодром *м* танкодром *(сугыш машиналарын йөртергә өйрәнү өчен җиһазланган җир участогы)*

танконедоступный танк үтә алмый торган

танк-тральщик *м* тралчы танк *(танкка каршы миналар кырып үтеп чыгу һәм һөҗүмгә баручы гаскәрләргә юл салу өчен кулланыла)*

таран *м* таран *(1. крепость стеналарын җимерү өчен кулланылган борынгы корал — бер башына тимер очлык кидерелгән авыр бүрәнә 2. үз корабыңның, очкычыңның яки танкыңның корпусы белән бәреп дошман корабын, очкычын яки танкын сафтан чыгару 3. күч. хәрби операция — фронтны өзү һәм дошман урнашкан җиргә барып керү)*

таранить таранларга, таран ясарга

тахометр *м* тахометр *(машина валының яки тәгәрмәчләрнең әйләнү тизлеген үлчи торган прибор)*

тачанка *ж* тачанка *(ачык әрҗәле, сиртмәле җиңел арба, гражданнар сугышы чорында атлы гаскәрдә пулемет йөртү өчен кулланылган)*

театр *м:* ~ **военных действий** сугыш хәрәкәтләре мәйданы

телеграмма *ж* телеграмма

~ **-«молния»** «яшен»-телеграмма *(бик ашыгыч телеграмма)*

телефонист *м* телефончы

телефонограмма *ж* телефонограмма *(телефон аша бирелгән хәбәр)*

темляк *м* бөлдерге *(шпага, кылыч, чыбыркы сапларындагы кулга кию өчен җайланган элмәк)*

темник *м* түмән башы *(ун мең сугышчыдан торган гаскәр белән җитәкчелек итүче татар хәрби башлыгы)*

темп *м* темп *(тизлек)*

теодолит *м* теодолит *(геодезик, астрономик тикшеренүләрдә, төзелеш эшләрендә, топографик план төшерүләрдә һәм атуны әзерләүдә кулланыла торган прибор)*

теплолокатор *м* җылылык локаторы *(инфракызыл локатор, оптик локаторның бер төре)*

теплообменник *м* җылы алмашкыч *(җылылыкны бер системадан икенче системага күчерүче җайланма)*

теплопроводность *ж* җылы үткәрүчәнлек *(җисемнең күбрәк җылынган өлешеннән азрак җылынган өлешенә җылылык күчү процессы)*

термит *м* термит *(янганда бик югары (2300—2700°С) температура бирә торган порошоксыман катнашма. Яндыргыч снарядларда, бомбаларда кулланыла)*

~ **ная бомба** термит бомба

~ **ная сварка** термит белән эретеп ябыштыру

термоядерн//ый термик төш ...ы, е; атом-төш ...ы, е

~ **ая реакция** термик төш реакциясе

~ **ое оружие** термик төш коралы

территориальн//ый территория ...ы; территориаль

~ **ая целостность** территория бөтенлеге, территориаль бөтенлек

~ **ый конфликт** территориаль конфликт *(территория мәсьәләсе буенча булган киеренкелек)*

террор *м* террор *(сәяси дошманны каты эзәрлекләү, үтерү, юк итү күренеше)*

террорист *м* террорчы

тесак *м* кыска кылыч *(сугышта кешене чабып яки чәнчеп үтерү өчен хезмәт итә торган ике йөзе дә үткен, киң һәм кыска корыч пластинадан гыйбарәт борынгы корал)*

теснина *ж* тарлавык, кысрык

теснить кысрыкларга

тестер *м* тестер *(радиоэлектрон аппаратураны тикшерү һәм төзәтү өчен кулланыла торган электр үлчәгеч прибор)*

тетрил *м* тетрил *(детонаторларда кулланыла торган шартлаучан матдә)*

техник *м* техник

авиационный ~ авиация техникы

техника *ж* техника

военная ~ хәрби техника

ракетная ~ ракета техникасы

~ **безопасности** куркынычсызлык техникасы

техобслуживание *с* техник хезмәт күрсәтү

техосмотр *м* техник карау

тип *м* тип, төр

~ **самолета** самолет тибы

тир *м* тир *(зур булмаган калибрлы кораллардан атарга өйрәтү өчен махсус җиһазланган бина)*

товсь! *(команда)* әзерлән!

токсичность *ж* агулылык, токсинлык

токсичный агулы

тол *м* тол *(шартлаткыч матдә)*

томагавк *м* томагавк *(Төньяк Америка индеецларының сугыш коралы)*

тоннаж *м* тоннаж *(1. судноларның тонна исәбе белән авырлыгы яки йөк сыйдырышлыгы 2. махс. автомобильнең, вагонның, очкычның һ.б. тонна исәбе белән йөк күтәрүчәнлеге)*
топливо *с* ягулык
высокооктановое ~ югары октанлы ягулык
высокосернистое ~ югары күкертле ягулык
газообразное ~ газсыман ягулык
двукомпонентное ~ ике компонентлы ягулык
дизельное ~ дизель ягулыгы
легковоспламеняющееся ~ тиз кабынучан ягулык
самовоспламеняющееся ~ үзлегеннән кабынучан ягулык
топливопровод *м* ягулык үткәргеч
топограф *м* топограф *(топография белгече)*
топографическ//ий топография ...ы, е; топографик
~ **ая карта** топографик карта
топография *ж* топография
торможение *с* тормозлау, туктату, тормоз салу
тормоз *м* тормоз
автоматический ~ автоматик тормоз
ручной ~ кул тормозы
торпеда *ж* торпеда *(сигарасыман формадагы үзйөрешле һәм үзидарәле су асты снаряды)*
реактивная ~ реактив торпеда
самонаводящаяся ~ үзе төбәлүче торпеда
управляемая ~ идарә ителә торган торпеда
торпедист *м* торпедачы
торпедный торпеда ...ы, е; торпедалы
~ **удар** торпеда һөҗүме
~ **аппарат** торпеда аппараты *(торпедалар белән ату һәм аларны саклау җайланмасы)*
торпедометание *с* торпеда ташлау *(очу аппаратыннан суда йөзүче цельгә таба авиация торпедасы ташлау)*
торпедоносец *м* торпеда йөртүче
торпедоносный торпедалы, торпеда йөртүче
точка *ж* нокта, урын, жир
~ **визирования** визир ноктасы
~ **наводки** төзәү (төбәү) ноктасы
нулевая ~ нуль ноктасы
~ **плавления** эрү ноктасы *(каты кристаллик матдәнең эрү температурасы)*
точность *ж* төгәллек
~ **бомбометания** бомба ташлау төгәллеге
~ **огня** ату төгәллеге
траверз *м* траверз *(судноның, очкычның алган курсына карата перпендикуляр юнәлеш)*
траверс *м* траверс *(1. окоп кырына өелгән туфрак өеме 2. махсус дамба)*
траектория *ж* траектория *(1. берәр җисемнең яки ноктаның хәрәкәт юлы 2. воен. пуля яки снарядның очып бару юлы)*
~ **падения** төшү траекториясе
баллистическая ~ баллистик траектория
параболическая ~ параболик траектория
трак *м* трак, буынтык
~ **и гусеницы танка** танк тәгәрмәче чылбыры буынтыклары
тракт *м* тракт, олы юл
трал *м* трал *(мина аулау җайланмасы)*
акустический ~ акустик трал
магнитный ~ магнитлы трал
минный ~ мина тралы
подрывной ~ шартлату тралы
траление *с* траллау *(1. трал белән мина тоту 2. диңгез төбен трал белән тикшерү)*
тральщик *м* тралчы *(1. трал белән җиһазланган судно 2. моряк, траллау эше белгече)*
трансмиссия *ж* трансмиссия *(хәрәкәтне двигательдән эш машинасына күчерә торган механизмнар)*
транспорт *м* транспорт
войсковой ~ гаскәр транспорты
десантный ~ десант транспорты
санитарный ~ санитария транспорты
транспортер *м* транспортер *(җәяүле гаскәр һәм йөкләр ташый торган хәрби машина)*
траншея *ж* траншея *(оборона позицияләрендәге барлык ут нокталарын тоташтыра торган һәм дошманга каршы ягына балчык, таш һ.б. нәрсәләр өелгән, снаряд, бомба кыйпылчыкларыннан саклану өчен хезмәт итүче тар, тирән, озын чокыр)*
трасса *ж* трасса *(1. (юнәлеш) юл сызыгы 2. юл)*

трассировать 1. *(әйбернең)* юнәлешен билгеләргә, трасса билгеләргә 2. эз калдырып очарга, яктыртып очарга *(снаряд, пуля турында)*
трассирующ//ий яктыртып очучы
~ая пуля яктыртып очучы пуля
требование *с* таләп, таләп язуы
~ на топливо ягулык алуга таләп язуы
тревог//а *ж (сигнал)* тревога
поднимать по ~е тревога буенча күтәрергә
боевая ~а сугышчан тревога
учебная ~а өйрәнү тревогасы
химическая ~а химик тревога
тревожный борчулы, хәвефле, шомлы, хафалы, хәвеф-хәтәрле
~ сигнал хәвефле сигнал
тренаж *м* тренаж *(күнегүләр системасы)*
тренажер *м* тренажер *(күнегүләр ясау җайланмасы)*
тренировать өйрәтергә, күнектерергә
тренировка *ж* күнекмә, күнегү, өйрәнү
тренога *ж* өчаяк
трескотня *ж* шатырдау, чатырдау, шатыр-шотыр итү, шарт-шорт килү
~ пулеметов пулеметлар шатырдавы
трехдюймовка *ж* өч дюймлы орудие
трехлинейн//ый: ~ая винтовка өч линияле винтовка
трехстволка *ж* өч көпшәле мылтык
трехступенчат//ый: ~ая ракета өч буынлы ракета
трибунал *м* трибунал *(1. хәрби яки гаять зур гражданлык җинаятьләрен карый торган гадәттән тыш махсус суд органы. Шул органның суд коллегиясе, судьялар 2. шул орган тарафыннан җинаятьләр тикшерү эше)*
военный ~ хәрби трибунал
триммер *м* триммер *(очкыч белән идарә итүне җиңеләйтү өчен рульгә яки элеронга беркетелгән кечкенә өслек)*
тринитротолуол (тротил) *м* тринитротолуол *(бик көчле шартлаучан матдә — мина, снаряд һ.б.ларда кулланыла)*
триплекс *м* триплекс *(1. гадәттә унификацияләнгән лафеты һәм төрле калибрлы көпшәләре булган өч төрдәге артиллерия орудиеләре системасы 2. ватылганда ярчыклар бирми торган өч катлы пыяла)*
триумф *м* триумф, тантана *(1. борынгы Римда сугыштан җиңеп кайтучы полководецны һәм аның гаскәрен каршы алу тантанасы 2. гаять зур җиңү, зур уңыш; тантана)*
тропосфера *ж* тропосфера *(җир атмосферасының стратосферага кадәр булган түбәнге катлавы)*
трос *м* трос, аркан *(диаметры 25 мм дан 102 мм га кадәр юанлыкта ишелгән корыч яки сүс аркан)*
тросомет *м* трос ыргыткыч *(һава буенча махсус снаряд белән трос ыргыту җайланмасы, ыргыту ераклыгы 380 метрга кадәр)*
тротил (тринитротолуол) *м* тротил
~овый эквивалент тротил эквиваленты *(атом-төш коралының куәтен үлчәү берәмлеге)*
трофей *м* трофей, ганимәт *(1. сугышта җиңгән яктан калган корал яки хәрби кирәк-яраклар 2. берәр җиңүне, уңышны, батырлыкны искә төшерә торган истәлекле әйбер)*
трубить быргы кычкыртырга
~ сбор җыелырга сигнал бирергә
трубопровод *м* үткәргеч торба
трюм *м* трюм *(корабның түбәнге палубасы белән төбе арасында йөк тутыру яки башка хаҗәтләр өчен махсус бушлык)*
тумблер *м* тумблер *(электр кучергеченең бер төре)*
тур *м* тур *(1. пуля яки ядрәдән саклану өчен эченә балчык тутырылган төпсез чыбык кәрзин. Шулай ук гидротехникада кулланыла 2. берничә этаптан торган вакыйга яки эш-хәрәкәтнең аерым этабы)*
турбина *ж* турбина
газовая ~ газ турбинасы
реактивная ~ реактив турбина
турбовинтовой турбовинтлы
турбореактивный турбореактив
турель ж турель *(хәрби очкычларда, танкларда, корабларда — туп яки пулеметны урнаштыру һәм әйләндерү өчен кулланыла)*
~ для спаренных пулеметов ике пулеметлы турель
хвостовая ~ койрык туреле, арткы турель
тыл *м* тыл *(1. сугышучы илнең фронт сызыгы артындагы бөтен территориясе 2. теге яки бу гаскәри берләшмә урнашкан, позиция тоткан урын ар-*

тындагы территория 3. хәрәкәттәге армия артында урнашкан һәм аны сугыш алып бару өчен бөтен кирәк-яраклар белән тәэмин итә торган ярдәмче гаскәри частьлар)
армейский ~ армия тылы
войсковой ~ гаскәр тылы
оперативный ~ оператив тыл
фронтовой ~ фронт тылы
тыловик *м* тылда хезмәт итүче
тыловой тылдагы, тыл ...ы, е
~ **госпиталь** тылдагы госпиталь
тяга *ж* тарту, тарту көче
тягач *м* тягач
тяговооруженность *ж* тарту көче белән коралланганлык

У

убежище *с* убежище *(снаряд, бомба яки агулы матдәләрдән саклану өчен махсус җиһазланган баз, подвал яки корылма, ныгытма)*
убить үтерергә
убойн//ый җимерү ...ы, е
~ **ая сила артиллерийского огня** артиллерия утының җимерү көче
убрать шасси! *(команда)* шассины җый!
убыть китәргә, чыгарга
~ **из полка** полктан китәргә
уважительн//ый 1. игътибарга алырлык, гафу итәрлек, кичерерлек, нигезле 2. ихтирамлы, хөрмәткә лаек
~ **ая причина** нигезле сәбәп
~ **ое отношение** ихтирамлы мөнәсәбәт
увековечить мәңгеләштерергә
~ **память павших героев** һәлак булган батырларның истәлеген мәңгеләштерергә
увеличить арттырырга, зурайтырга
увольнение *с* чыгару, эштән чыгару, азат итү
~ **в запас** запаска чыгару
~ **в отпуск** отпускка чыгару
~ **в отставку** отставкага чыгару
~ **на берег** ярга чыгу *(корабтан кыска вакытлы ялга ярга чыгу)*
~ **с военной службы** хәрби хезмәттән азат итү
угломер *м* почмак үлчәгеч
угроза *ж* куркыныч, янау
~ **воздушного нападения** һава һөҗүме куркынычы
~ **войны** сугыш куркынычы

удаление *с* 1. алу, алып ташлау 2. ерагаю, ераклашу
~ **взрывателя** шартлаткычны алып ташлау
удар *м* 1. сугу, бәрү, ору, чабу, удар 2. *куч. (җитез һөҗүм)* бәреп керү
~ **прикладом** приклад белән сугу
сабельный ~ кылыч белән чабу
~ **с фланга** флангтан бәреп керү
~ **с воздуха** һавадан һөҗүм
ядерный ~ атом-төш һөҗүме
ударник *м* ударник, бәргеч
ударн//ый удар *(хәлиткеч һөҗүм ясый торган)*
~ **ая армия** удар армия
удерживать тотып калырга, җибәрмәскә, ычкындырмаска, төшермәскә, саклап калырга
удержаться торып калырга, урында калырга, тора алырга
~ **на старых позициях** иске позицияләрдә торып калырга
удостоверение *с* таныклык
~ **личности** шәхес таныклыгы
удостоить бирергә, бүләкләргә
удостоиться лаек булырга
~ **правительственной награды** хөкүмәт бүләгенә лаек булырга
удушение *с* буу, буылу, тончыгу, тончыктыру
удушливый тончыктыргыч, буылдыргыч
~ **газ** буылдыргыч газ
узел I *м* узел, төен, үзәк
железнодорожный ~ тимер юл узелы
~ **связи** элемтә үзәге
узел II *м* узел *(корабның диңгездә йөзү тизлеген үлчәү берәмлеге)*
узость *ж* 1. тарлык, кысрыклык, кысанлык 2. *куч.* тар карашлылык, чикләнгәнлек, сайлык
указание *с* 1. күрсәтү 2. күрсәтмә
указатель *м* 1. күрсәткеч 2. белешмә
~ **азимута** азимут күрсәткече
~ **дорог** юл күрсәткече
~ **скорости** тизлек күрсәткече
~ **прохода** үтү юлы күрсәткече *(мина кырында)*
укладчик *м* салучы, түшәүче, өючә, җыючы, тутыручы
~ **парашютов** парашют җыючы
уклонение *с* 1. тайпылу 2. авышу 3. борылу, качарга тырышу

укомплектованность *ж* комплектланган (тулыландырылган) булу

укомплектовывать комплектларга, комплектка тутырырга, тулыландырырга

укреплени//е *с* 1. ныгыту 2. ныгытма

долговременные ~я озак вакытлы ныгытмалар

укрепи//ться ныгып урнашырга

полк ~лся на склонах горы полк тау битләрендә ныгып урнашты

укрывать 1. яшерергә, яшереп калырга (тотарга), качырырга, качырып калырга (тотарга) 2. ябарга, капларга, бөркәргә, төрергә

укрытие *с* ышык, ышыклану урыны

улан *м* улан *(патша һәм кайбер чит ил армияләрендә атлы гаскәрдәге солдат яки офицер)*

уловк//а хәйлә, сылтау, әмәл

пуститься на ~и хәйләгә керешергә, хәйлә корырга

ультиматум *м* ультиматум

предъявить ~ ультиматум белдерергә

ультразвук *м* ультратавыш

ультракоротковолновый ультракыска дулкынлы

умформер *м* умформер *(аз көчәнешле даими токны югары көчәнешле алмаш токка әверелдерү җайланмасы. Радиоаппаратураны туендыру өчен кулланыла)*

универсальн//ый универсаль, күпьяклы, күпкырлы

~ая артиллерия универсаль артиллерия *(һавадагы, диңгездәге һәм җирдәге цельләргә ата алучы кораб артиллериясе төре)*

унификация *ж* унификация, унификацияләштерү

унифицировать унификацияләргә, бердәйләштерергә

уничтожить юк итәргә, кырып бетерергә, башына җитәргә

~ врага дошманны юк итәргә

уничтожающий һәлакәтле, үтергеч, һәлак иткеч

~ огонь артиллерии артиллериянең һәлакәтле уты

унтер-офицер *м* унтер-офицер *(патша армиясендә һәм кайбер чит ил армияләрендә кече командир дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәгә ия булган гаскәри)*

уплотнение *с* тыгызлану

уплотненность *ж* тыгызлык

уползти шуышып, үрмәләп китәргә (качарга)

упор *м* терәк, таяныч

боевой ~ затвора затворның атута әзерлек терәге

выстрелить в ~ терәп атарга

упорн//ый каты, кискен, чыдамлы

~ая борьба кискен көрәш

упорство *с* 1. ныклык, нык тору, катылык 2. тискәрелек, үҗәтлек

управлени//е *с* 1. идарә итү, йөртү 2. идарә

~е автомобилем автомобиль йөртү

~е войсками гаскәр белән идарә итү

~е кадров кадрлар идарәсе

~е огнем ут белән идарә итү

~е по радио радио буенча идарә итү

дистанционное ~е ерактан идарә итү

разведывательное ~е разведка идарәсе

ручное ~е кул белән идарә итү

рычаги ~я идарә рычаглары

центральное ~е үзәк идарә, үзәктән идарә итү

управляемость *ж* идарә ителеш, идарә ителү үзлеге

сохранить ~ самолета очкычның идарә ителү үзлеген сакларга, очкыч белән идарәне сакларга

управляем//ый идарә ителә торган

~ая ракета идарә ителә торган ракета

~ый по радио радиоидарәле

упражнение *с* күнегү, күнекмә

упразднить юкка чыгарырга, бетерергә

упреждение *с* алдан хәстәрен күрү, алдан эшләү, уздырып эшләү, алдан өлгерү

~ цели хәрәкәт итүче цельнең урын алмаштыруын (билгеләнгән ноктага барып җитү вакытын) исәпләү

уравнение *с* 1. тигезләү, тигезләштерү, тинләштерү 2. тигезләмә

уран *м* уран *(атом энергиясе алу өчен кулланыла торган радиоактив химик элемент)*

урановый уран ...ы, е

~ котел уран казаны *(авыр төшләр бүленгәндә чылбыр реакция булдыру өченураннан плутоний аерып алу җайланмасы)*

уровень *ж* 1. *приб.* тигезләвеч 2. тигезлек, биеклек, дәрәҗә

уровнемер *м* биеклек үлчәгеч *(савыт-*

тагы сыекчаның биеклеген үлчәү приборы)
урядник *м* урядник *(1. патша армиясенең казак гаскәрләрендә хезмәт итүче унтер-офицер 2. патша Россиясендә өяз полициясенең түбән чины)*
усиление *с* көчәйтү, куәтләндерү, көчен арттыру, куәтен арттыру
~ **бдительности** сизгерлекне көчәйтү
усилитель *ж* көчәйткеч
гидравлический ~ гидравлик көчәйткеч
магнитный ~ магнитлы көчәйткеч
низкочастотный ~ түбән ешлыклы көчәйткеч *(радиоалгычта тавыш ешлыгындагы электр тирбәнешләрен көчәйтүче каскад)*
~ **мощности** егәрлек көчәйткече
~ **отдачи** кире бәрү көчәйткече
ускорение *с* тизләнеш *(тизлекнең вакыт берәмлегендә үзгәрүен күрсәтә торган зурлык)*
угловое ~ почмакча тизләнеш
~ **свободного падения** тоткарсыз төшү тизләнеше
центростремительное ~ үзәккә омтылу тизләнеше
ускоритель *м* тизләткеч
стартовый ~ старт тизләткече *(ракетаны хәрәкәтккә китерү һәм аңа марш двигателен тоташтыруны тәэмин итүче тизлек бирү өчен хезмәт итә торган двигатель)*
услови//е *с* шарт, таләп, килешү, кагыйдә
~ **я капитуляции** капитуляция шартлары
~ **я перемирия** вакытлы килешү шартлары
условн//ый шартлы, уйланма, килешенгән
~ **ая линия** уйланма сызык
~ **ый знак** шартлы билге
~ **ый приговор** шартлы хөкем
усложненность *ж* катлаулылык, четереклелек, кыенлык
усмирить буйсындырырга, тынычландырырга, бастырырга
~ **мятеж** фетнәне бастырырга
усобица *ж* үзара дошманлык, ызгыш
усомниться шикләнергә, шиккә төшәргә
~ **в верности сообщения** хәбәрнең дөреслегенә шикләнергә
успех *м* уңыш
боевой ~ сугышчан уңыш
добиться ~ **а** уңышка ирешергә
тактический ~ тактик уңыш
устав *м* устав *(нәрсәнең дә булса үтәлү яки кулланылу тәртибен билгели торган кагыйдәләр җыелмасы)*
соблюдать ~ уставны үтәргә
~ **внутренней службы** эчке хезмәт уставы
~ **военно-воздушных сил** хәрби-һава көчләре уставы
боевой ~ сугышчан устав
дисциплинарный ~ дисциплинар устав
полевой ~ кыр уставы
строевой ~ саф уставы
уставный устав ...ы, е; уставта каралган
установка *ж* 1. күрсәтмә, директива 2. җайланма, корылма 3. урнаштыру, көйләү, кую
~ **мин** миналар кую
~ **прицела** прицелны көйләү
артиллерийская ~ артиллерия җайланмасы
дегазационная ~ дегазация җайланмасы
опреснительная ~ су төчеләтү корылмасы
отопительная ~ җылыту җайланмасы
силовая ~ энергия җайланмасы
фильтровальная ~ фильтрлау җайланмасы
холодильная ~ суыткыч җайланма
устаревший искергән, гамәлдән чыккан
усто//й *м* терәк, таяныч, багана
быки и береговые ~ **и моста** күпернең терәкләре һәм яр таянычлары
устойчивость *ж* тотрыклылык
устоять нык торырга, бирешмәскә
устремиться ябырылырга, ташланырга, җибәрергә
устройство *с* 1. кору, салу, булдыру, оештыру, җайга салу, урнаштыру 2. корылма, җайланма
ухаб *м* чокыр-чакыр, сикәлтә *(юлда)*
ухнуть гөрселдәргә, дөпелдәргә
участок *м* участок, бүлемтек, кишәрлек; өлеш; тармак, өлкә
~ **обороны полка** полкның оборона участогы
заминированный ~ миналанган участок
зараженный ~ агуланган участок

открытый ~ **местности** ялан җир
учеба *ж* уку, белем алу, өйрәнү
боевая ~ сугышчан укулар
летная ~ очарга өйрәнү
учени//е *с* өйрәнү, күнегү
тактические ~**я** тактик өйрәнүләр
штабные ~**я** штаб өйрәнүләре
учет *м* исәп-хисап, исәпкә алу, барлау, теркәү
училище *с* училище *(белгечләр әзерли торган махсус уку йорты)*
бронетанковое ~ бронетанк училищесы
воздушно-десантное ~ һава десанты училищесы
высшее военное ~ югары хәрби училище
высшее военно-морское ~ югары хәрби-диңгез училищесы
высшее военно-политическое ~ югары хәрби-политик училище
командное ~ командирлар училищесы
летное ~ очучылар училищесы
мореходное ~ диңгез училищесы
общевойсковое ~ гомумгаскәри училище
штурманское ~ штурманнар училищесы
учреждение *с* учреждение
военное ~ хәрби учреждение
~ **тыла** тыл учреждениесе
ущерб *м* зыян, зарар, каза, югалту
уязвимость *ж* йомшаклык, зәгыйфьлек
уязвим//ый йомшак, зәгыйфь
~**ые места** йомшак яклары
уяснение *с* ачыклау, аныклау
~ **задачи** бурычны ачыклау

Ф

факел *м* факел
пусковой ~ кабызгыч факел
факсимиле *с* факсимиле *(кульязманың, имзаның, документның фотография яки басма ярдәмендә төшереп алынган күчермәсе)*
факсимильн//ый факсимиле
~**ая связь** факсимиле элемтә
~**ый аппарат** факсимиле аппараты
факт *м* 1. факт, чынбарлык 2. факт, мисал, очрак
фактор *м* фактор *(берәр процессны, вакыйганы тудыручы шарт, сәбәп)*
~ **внезапности** көтелмәгәнлек (кинәтлек) факторы
~ **времени** вакыт факторы
~ **местности** урын факторы
фал *м* фал, бау, аркан *(1. корабларда җилкәннәрне, сигнал флагларын һ.б. күтәрү өчен хезмәт итә торган бау 2. парашютны кеше катнашыннан башка ачу өчен, бер очы очкыч кабинасына, икенче очы парашют бөҗрасына беркетелгән бау)*
фаланга *ж* фаланга *(1. борынгы грекларда җәяүле гаскәрнең берничә рәтле тыгыз сафка тезелгән сугышчан тәртибе 2. күч. тигез итеп тезелгән саф)*
фалинь *ж* фалинь *(шлюпканың борынына яки койрык өлешенә беркетелә торган бау; фалинь ярдәмендә шлюпка буксирга алына, пристаньга яки судноның бортына бәйләп куела)*
фальконет *м* фальконет *(XVI—XVIII гасырларда кораллануда булган, кургаш снарядлар белән аткан кече калибрлы туп)*
фальшборт *м* фальшборт *(судно бортының югары палубадан өстәрәк борт тышлыгы дәвамы)*
фальшкиль *м* фальшкиль *(суднога тотрыклылык бирү яки кильне ватылудан саклау өчен соңгысының астына беркетелә торган агач яки металл борыс)*
фарватер *м* фарватер *(диңгез, күл һәм елгаларда судноларның йөри алырлык куркынычсыз, гадәттә сигнал билгеләре булган, су юлы)*
фарис *м* фарис *(җайдак, атка атланган гарәп сугышчысы)*
фартук *м* фартук, япма
защитный ~ саклагыч япма
фас *м* фас *(траншеяның туры өлеше)*
фашина *ж* фашина *(чыбыклар бәйләме, камыш көлтәсе; хәрби инженерлык эшләрендә дренаж, туфракны ныгыту максаты белән сазлы урыннарда юлларны түшәү өчен һ.б. җирләрдә кулланыла)*
фейерверк *м* фейерверк *(тиз кабынучан махсус катнашмаларны яндырудан хасил була торган төрле төстәге декоратив утлар)*
фейерверкер *м* фейерверкер *(патша армиясендәге артиллерия унтер-офицеры)*
фельдмаршал *м* фельдмаршал *(патша Россиясендә һәм кайбер чит илләрдә хәзер дә иң югары хәрби дәрәҗә; шул дәрәҗәдәге кеше)*

фельдфебель *м* фельдфебель *(патша армиясендә һәм кайбер чит ил армияләрендә рота командирының эчке тәртипне саклауда һәм хуҗалык эшләрендә ярдәмчесе)*
фельдъегерь *м* фельдъегерь *(аеруча әһәмиятле һәм ашыгыч ящерен хәбәр язылган кәгазьләрне илтүче курьер)*
фелюга *ж* фелюга *(көньяк диңгезләрдә йөри торган зур булмаган җилкәнле яки моторлы промысел судносы)*
фигура *ж* фигура
~ **высшего пилотажа** югары пилотаж фигурасы
фиксатор *м* фиксатор, беркеткеч
~ **ствола** көпшә беркеткече
фиктивный фиктив, ялган
~ **документ** ялган документ
фикция *ж* фикция, уйдырма, ялган
филер *м* филер, шымчы *(полиция агенты)*
фильтр *м* фильтр, сөзгеч
~ **грубой очистки** тупас чистарту фильтры
~ **тонкой очистки** пөхтә чистарту фильтры
~ **-отстой** тондыргыч фильтр
цветной ~ төсле фильтр
фильтрат *м* фильтрат, сөзелмә
фильтровальн//ый фильтр ...ы, е; фильтрлау ...ы, е
~ **ая установка** фильтрлау җайланмасы
фильтровать фильтрларга, сөзәргә
фильтровый фильтр ...ы, е; фильтрлы
финка *ж* финка *(кыныга тыгып йөртелә торган киң һәм кыска хәнҗәр)*
фитиль *м* филтә
флаг *м* флаг
водрузить ~ флаг кадау
флагман *м* флагман *(1. эре хәрби кораблар берләшмәләренең — эскадра, дивизия, отряд — баш командиры; баш корабта үз флагын күтәрү хокукына ия 2. эскадра яки кораблар берләшмәсенең баш командиры утырган җитәкче кораб, очкыч; шулай ук шул районнагы иң зур кораб, очкыч)*
флагшток *м* флагшток *(корабларда, биналарда һ.б. урыннарда флаг күтәрә торган колга)*
флажок *м* флагчык, флажок
сигнальный ~ сигнал флажогы
фланг *м* фланг *(гаскәр тезелешенең, сафның, фронтның уң яки сул кырые)*
правый ~ уң фланг
атаковать с ~ а флангтан һөҗүм итәргә
фланговый фланг ...ы, е; фланг ягыннан ..., флангтан ..., флангтагы
~ **огонь** фланг уты
~ **удар** фланг һөҗүме
фланк *м* фланк *(крепость коймасының яки кырдагы хәрби ныгытманың флангларын каплау өчен билгеләнгән зур булмаган туры участогы)*
фланкер *м* фланкер *(XVIII—XIX гасырларда атлы гаскәрдә — дошманның кинәттән һөҗүмен булдырмау өчен хәрәкәт итүче отрядның флангларында баручы атлы күзәтче)*
флаттер *м* флаттер *(очкыч аппаратларның канатларында, койрык яссылыкларында һәм башка элементларында үзеннән-үзе була торган вибрацияләр)*
флегматизатор *м* флегматизатор *(туп көпшәләре каналларын артык кызудан саклау өчен снаряд зарядларында кулланыла торган матдәләр — парафин, вазелин, балавыз һ.б.)*
флешь *ж* флешь *(очы белән дошманга төбәлгән җәенке почмак рәвешендәге кыр ныгытмасы)*
флигель-адъютант *м* флигель-адъютант *(патша, император даирәсендә билгеләнгән офицер яки армия баш командантының йомышларын үтәүче офицер, шул чиндагы кеше)*
флор *м* флор *(корыч судно шпангоутының аскы өлеше)*
флот *м* флот *(хәрби корабларның эре берләшмәсе)*
военно-морской ~ хәрби-диңгез флоты
москитный ~ москит флоты
подводный ~ су асты флоты
ракетоносный ~ ракета йөртүче флот
флотилия *ж* флотилия
~ **подводных лодок** су асты көймәләре флотилиясе
флотский флот ...ы, е
фляга *ж* фляга *(савыт)*
фок-мачта *ж* фок-мачта *(суднода алгы мачта)*
фон *м* фон *(1. тавыш көчен билгеләү берәмлеге 2. берәр нәрсәнең арткы планы яки күренеше)*
фонарь *м* фонарь
откидной ~ күтәрелмәле фонарь
сдвижной ~ шудырмалы фонарь
сигнальный ~ сигнал фонаре

фонд *м* фонд *(нәрсәнең дә булса запасы, тупланмасы, резервы)*
обменный ~ обмундирования обмундирование (формалы кием) алмаштыру фонды
фордевинд *м* фордевинд *(юналеше буенча судноның курсына туры килүче җил)*
форма *ж* форма, форма киеме
военная ~ хәрби форма
зимняя ~ одежды кышкы кием формасы
парадная ~ одежды парад киеме
повседневная ~ одежды көндәлек кием
полевая ~ одежды кыр киеме, кыр формасы
установленная ~ одежды билгеләнгән (уставта каралган) форма (форма киеме)
формировать формалаштырырга, төзергә, оештырырга, булдырырга
~ полк полк төзергә
формуляр *м* формуляр *(нинди дә булса корылма, механизм, прибор һ.б.ларны файдалану, аларның бозылуы, ремонт һ.б. турында эзлекле тәртиптә язылa торган махсус кенәгә яки бланк)*
~ минного поля мина кыры формуляры
~ на боеприпасы сугыш кирәк-яраклары формуляры
тактический ~ корабля корабның тактик формуляры
форпик *м* форпик *(судноларда форштевень кырыенда урнашкан борын бүлеге)*
форпост *м* форпост *(сакчы частьларның алгы посты, шулай ук чик буендагы ныгытылган пункт)*
форсировать 1. көчәйтергә, тизләтергә, ашыктырырга 2. кичәргә, ...аша чыгарга, үтәргә
~ события вакыйгаларны тизләтергә
~ реку елга аша чыгарга
форсунка *ж* форсунка *(ягулык бөркү җайланмасы)*
струйная ~ агынтылы форсунка
центробежная ~ үзәктән кугыч форсунка
форт *м* форт *(крепость корылмалары системасында мөстәкыйль оборона тотарлык аерым ныгытма; зур булмаган крепость)*
фортификация *ж* фортификация *(1. сугыш мәйданын ныгыту турындагы хәрби инженерлык фәне 2. хәрби инженерлык корылмалары)*
долговременная ~ озак вакытлы фортификация
форштевень *м* форштевень *(судноның борын өлеше)*
фосген *м* фосген *(газ)*
фотографирование *с* фотога (сурәткә, рәсемгә) төшерү
фотоэлемент *м* фотоэлемент *(фотоэффект күренешенә нигезләнеп төзелгән прибор. Аңа яктылык төшкәч, электр тогы барлыкка килә)*
фрегат *м* фрегат *(XVII—XIX гасырларда — өч мачталы җилкәнле кораб; хәзерге сакчы хәрби кораб)*
фронт *м* фронт *(1. рәтләргә тезелгән хәрби сафның алгы ягы 2. дошманга каршы урнашкан гаскәрләрнең алгы ягы һәм аларның таралыш урыны, сызыгы 3. сугыш бара торган һәм шул вакытта хәрәкәттәге (сугыштагы) армия урнашкан урын, район. Шундый районнардагы иң зур хәрби көчләр берләшмәсе)*
быть на ~е фронтта булырга
восстанавливать ~ фронтны яңадан торгызырга
занимать ~ фронтка урнашырга
прорвать ~ фронтны өзәргә
удерживать ~ фронтны тотарга
фронтальн//ый фронталь
~ая атака фронталь атака
фронтовик *м* фронтовик *(фронтта хәрәкәттәге частьларда сугышучы яки сугышкан кеше)*
фронтовой фронт ...ы, е; фронттагы ...
~ госпиталь фронт госпитале
фрунт *м* фрунт *(гаскәр сафы)*
фугас *м* фугас *(шартлаткыч матдә заряды)*
~ная бомба фугаслы бомба
фузея *ж* фузея *(чакматашлы борынгы мылтык)*
фузилер *м* фузилер *(фузея белән коралланган XVII—XVIII гасырлар солдаты)*
фураж *м* фураж *(терлек азыгы)*
фуражка *ж* фуражка *(җәй-көз киелә торган козырёклы баш киеме)*
форменная ~ форма фуражкасы
фургон *м* фургон *(1. йөк автомобиленең яки тагылманың өсте ябулы кузовы 2. өсте ябулы арба)*
фурштат *м* фурштат *(патша Россиясендә хәрби олау солдаты)*

футеровка *ж* футеровка, эчлек
футляр *м* футляр *(нинди дә булса приборны, инструментны салып куя торган тартма)*
футшток *м* футшток *(диңгездә, елгада, күлдә артык тирән булмаган су биеклеген үлчәү өчен рейка)*
фухтель *м* йөз *(кылычның яки башка салкын коралның кисә торган өлешенең яссы ягы)*
фюзеляж *м* фюзеляж *(очкычның корпусы, каркасы)*

Х

хаки *с* хаки *(1. күрәнсу яшел төс 2. шул төстәге тукыма, шундый тукымадан тегелгән форма киеме)*
халат *м* халат *(күлмәк өстеннән кия торган махсус эш киеме)*
защитный ~ саклагыч халат
маскировочный ~ маскировка халаты
харакири *с* харакири *(Япониядә самурайларның үз эчләрен ярып, үз-үзләрен үтерү йоласы)*
характер *м* 1. характер, холык, табигать 2. төс, сыйфат, үзенчәлек, характер
~ **местности** урын(нын) үзенчәлеге
~ **почвы** туфрак(нын) үзлеге
характеристика *ж* характеристика, тасвирлама, сыйфатлама
боевая ~ сугышчан характеристика
силовая ~ көч характеристикасы
эксплуатационная ~ эксплуатацион характеристика
химик *м* химик *(1. химия белгече, химия өлкәсендә эшләүче галим 2. химия промышленносте хезмәткәре)*
химическ//ий химик, химия ...ы
~**ое оружие** химик корал
~**ий снаряд** химик снаряд
хирургия *ж* хирургия *(1. авыруны операция ясап дәвалау 2. медицинаның авыруларны операция ясап дәвалау алымнарын өйрәнә торган бүлеге)*
хитрость *ж* хәйлә, хәйләкәрлек
взять ~**ю** хәйлә белән алдырырга
пуститься на ~ хәйлә корырга
хлебопек *м* икмәк пешерүче
хлопа//ть шартларга, шапылдарга, шартлатырга, шапылдатырга
~**ют выстрелы** аткан тавышлар ишетелә
хлопок *м* шартлау тавышы, шарт иткән тавыш
хлорировать хлорларга *(хлор белән эшкәртергә)*
хлорпикрин *м* хлорпикрин *(лайлалы ярыга тәэсир итә торган, көчле исле, төссез, агулы авыр сыекча)*
хлястик *м* хлястик *(шинель, пальто һ.б. киемнәрнең арттактасын бил турысында бераз җыеп тору өчен төймәгә эләктереп куела торган тар гына тукыма кисәге)*
хобот *м* хобот *(пулемет яки туп лафетының арткы өлеше)*
ход *м* 1. йөреш 2. барыш 3. алым, ысул 4. керү юлы, ишек
~ **винта** винт йөреше
~ **сражения** сугыш барышы
~**ы сообщения** йөрү юллары *(окопларда)*
задний ~ артка йөреш, артка чигү
полный ~ бик тиз бару, тулы тизлек
потайной ~ яшерен юл
прибавить ~ тизлекне арттырырга
тихий ~ әкрен бару
холостой ~ буш йөреш, бушка эшләү *(мәс., моторның йөкләнешсез эшләве)*
холм *м* калкулык, үр
холмик *м* таучык, калкулык
холмист//ый калкулыклы
~**ая местность** калкулыклы урын
холостой 1. буш, файдасыз 2. ядрәсез, пулясыз
~ **патрон** пулясыз патрон
хомутик *м* камытча, беркеткеч *(винтовкада, пулеметта төзәгеч рамның кучерелә торган өлеше — аркылы планка)*
~ **прицела** төзәгеч камытчасы
хордоугломер *м* хордоугломер *(артиллериядә кулланыла торган махсус үлчәү приборы)*
хоронить 1. күмәргә, җирләргә 2. *күч.* онытырга
хорониться яшеренергә, качарга
хоругвь *ж иск.* хоругвь *(гаскәр байрагы)*
хорунжий *м* хорунжий *(1. иск. гаскәрдә байрак йөртүче 2. патша Россиясендә казак гаскәрләрендә подпоручикка һәм корнетка тиң булган беренчел офицер чины; шул чиндагы кеше)*

храбрость *ж* батырлык, кыюлык, гаярьлек
хранилище *с* саклау урыны
хранить сакларга, тотарга, саклап тотарга
~ **тайну** сер сакларга
хронометр *м* хронометр *(навигациядә, аэронавигациядә, геодезиядә кулланыла торган аеруча төгәл сәгать)*
хунта *ж* хунта *(властьны үз кулына законсыз тартып алучы һәм диктатор алымнары белән идарә итүче заговорчылар төркеме)*
военная ~ хәрби хунта

Ц

цапфа *ж* цапфа *(валның яки күчәрнең подшипникка таянган өлеше)*
цевье *с* көбәк
цейхгауз *м* цейхгауз *(хәрби склад)*
целеуказание *с* цель күрсәтү
целик *м* целик *(туп һәм пулеметларда прицелның шудырма өлеше)*
целиться төзәргә, төбәргә
~ **в мишень** мишеньгә төзәргә
цель *ж* 1. цель, мәрә *(атып яки ыргытып тидерергә тиешле урын)* 2. максат
выходить на ~ цельгә чыгарга
засекать ~ цельнең урынын ачыкларга
наводить на ~ цельгә төзәргә
обнаруживать ~ цельне табарга
перехватывать ~ цельне эләктереп алырга
попадать в ~ цельгә тидерергә
следить за ~**ю** цельне күзәтергә
сопровождать ~ цельне эзәрләп барырга
быстроходная ~ тиз йөрешле цель
движущаяся ~ хәрәкәт итүче цель
маневрирующая ~ маневр ясаучы цель
надводная ~ су өсте целе
надземная ~ җир өсте целе
невыгодная ~ уңайсыз цель
низколетящая ~ түбән оча торган цель
одиночная ~ ялгыз цель
подвижная ~ хәрәкәтчән цель
точечная ~ ноктасыман цель
цельнометаллический тоташ металл ..., тоташ металлдан эшләнгән
цензура *ж* цензура
центр *м* үзәк
~ **взрыва** шартлау үзәге
~ **рассеивания** сибелү (таралу) үзәге
~ **тяжести** авырлык үзәге
~ **управления огнем** ут белән идарә итү үзәге
летно-испытательный ~ очу-сынау үзәге
учебный ~ өйрәнүләр үзәге *(составында өйрәнү объектлары — полигон, танкодром, автодром, атарга өйрәнү урыны һ.б. булган һәм сугышчан хәзерлек мәсьәләләрен практик үзләштерү өчен билгеләнгән хәрби часть)*
централ *м* централ *(патша Россиясендә үзәк төрмә)*
централизация *ж* үзәкләштерү, үзәккә туплау
централит *м* централит *(агулый торган матдә)*
централка *ж* централка *(мылтыкның бер төре)*
центрифуга *ж* центрифуга *(1. очучыларга, космонавтларга күнегүләр ясау өчен һәм приборларны сынау өчен махсус җайланма 2. катнаш матдәләрне үзәктән куу көче белән состав өлешләргә аера торган аппарат)*
центурион *м* центурион *(борынгы Рим гаскәрендә центурия башлыгы)*
центурия *ж* центурия *(борынгы Римда йөз кешедән торган хәрби подразделение)*
цепн//ой чылбырлы
~**ая передача** чылбырлы тапшыру
цеппелин *м* цеппелин *(куп йөк күтәрешле, ләкин бик акрын хәрәкәт итүче металл каркаслы дирижабль)*
цепь *ж* цепь, чылбыр, тезмә
наступать ~**ю** цепь белән һөҗүм итәргә
стрелковая ~ укчылар тезмәсе
электрическая ~ электр чылбыры
якорная ~ якорь чылбыры
цинка *ж* цинка, *(һава үткәрми торган итеп ясалган)* әрҗә, контейнер
патронная ~ патрон цинкасы
цирик *м* цирик *(Монголия армиясе солдаты)*
циркуль *м* циркуль, җәзбә *(әйләнә сызу һәм туры сызыкның озынлыгын үлчәү өчен як-якка аерыла торган ике япьле сызым коралы)*
циркуляр *м* циркуляр *(күрсәтмә)*
цистерна *ж* цистерна *(сыекча яки газ саклау һәм ташу өчен зур резервуар;*

шундый резервуары булган вагон, автомобиль һ.б.)
балластная ~ балласт цистернасы
железнодорожная ~ тимер юл цистернасы
топливная ~ ягулык цистернасы
цитадель *ж* цитадель *(крепость эчендә мөстәкыйль оборона тотарлык итеп ныгытылган корылма)*
циферблат *м* циферблат *(үлчәгеч приборларда шкалалар, цифрлар һәм билгеләр төшерелгән пластинка)*
цоколь *м* цоколь *(1. стенаның тышка чыгып торган аскы өлеше 2. лампочка төплеге)*

Ч

чал *м* аркан, чылбыр *(пристаньнарда пароходларны һ.б. бәйләп кую өчен)*
чан *м* чан *(зур мичкә)*
отстойный ~ тондыру чаны
час «Ч» «Ч» сәгате *(һөҗүм итүче гаскәрләрнең дошман оборонасының алгы чигенә барып житүе, су тоткарлыгын кичә башлавы, һава (диңгез) десанты ташлау вакытын шартлы билгеләү)*
часово//й *м* часовой, сакчы, каравыл
выставить ~**го** часовой куярга
сменить ~**го** часовойны алыштырырга
~**й при знамени** байрак сакчысы
частица *ж* кисәкчә
радиоактивная ~ радиоактив кисәкчә
частота *ж* ешлык
~ **колебаний** тирбәнү ешлыгы *(секунд эчендә ясалган тирбәнешләр саны)*
~ **тока** ток ешлыгы *(электр йөртү көченең бер секунд эчендә булган тулы тирбәнүләре саны)*
низкая ~ түбән ешлык
частотомер *м* ешлык үлчәгеч *(механик һәм электрик ешлыкларны үлчи торган прибор)*
частый еш, еш-еш
~ **пулеметный** огонь пулеметның еш утлы
част//ь *ж* 1. часть *(гаскәри берәмлек)* 2. часть *(деталь)* 3. бүлек 4. өлеш, кисәк
формировать ~**ь** часть төзергә
~**ь обеспечения** тәэмин итү часте
~**ь ПВО** һава һөҗүменә каршы оборона (ПВО) часте
авиационная ~**ь** авиация часте
автомобильная ~**ь** автомобильләр часте
войсковая ~**ь** хәрби часть
гвардейская ~**ь** гвардия часте
запасная ~**ь** запас часть
инженерная ~**ь** инженерлык часте
казенная ~**ь ствола** көбәкнең арткы өлеше
моторизованная ~**ь** моторлаштырылган часть
отдельная ~**ь** аерым часть
откатные ~**и** *арт.* кире кайтым частьлары
пехотная ~**ь** җәяүле гаскәр часте, пехота часте
подвижные ~**и** *(в технике)* хәрәкәтләнүче частьлар
поддерживающая ~**ь** ярдәм часте
проезжая ~**ь дороги** юлның хәрәкәт өлеше
смешанная ~**ь** катнаш часть
стрелковая ~**ь** укчы часть
чека *ж* чикә
предохранительная ~ саклагыч чикә
чекан *м* чәкән *(борынгы корал)*
человеко-час *м* кеше-сәгать *(эшче көче берәмлеге)*
чертеж *м* сызым
честь *ж* 1. честь 2. намус
отдавать ~ честь бирергә
четырехствольный дүрт көпшәле
чехол *м* чехол, тышлык, япма
чин *м* чин, дәрәҗә
офицерский ~ офицерлык дәрәҗәсе
численность *ж* сан, исәп
~ **войска** гаскәр саны
штатная ~ штат саны
численн//ый сан ...ы, е; исәп ...ы, е; санча, сан ягыннан
~**ый состав войск** гаскәрнең санча составы
~**ое превосходство** сан ягыннан өстенлек
число *с* сан
октановое ~ октан саны *(бензинның кабыну тизлеген күрсәтә)*
передаточное ~ күчерү саны *(иярүче шкивның әйләнүләр санын йөртүче шкивның әйләнүләр санына бүлүдән чыккан сан)*
цетановое ~ цетан саны *(дизель ягулыгының үзлегеннән кабыну күрсәткече)*
член *м* әгъза, член
~ **военного совета** хәрби совет әгъзасы
членовредительство *с* әгъза бозу

чрезвычайный гадәттән тыш
чтить хөрмәтләргә, олыларга, искә алырга
~ **память погибших** һәлак булганнарны искә алырга
чувствительность *ж* 1. сизгерлек, хисләлек 2. сизелерлек
~ **прибора** приборның сизгерлеге *(прибор үлчи ала торган иң кечкенә кыйммәт)*
чума *ж* чума, үләт *(йогышлы авыру)*
чуткость *ж* сизгерлек, саклык, үткенлек
чутье *с* сиземләү
чучело *с* карачкы

Ш

шаблон *м* шаблон, калып, өлге, күчергеч
шаг *м* адым, атлау, йөреш
короче ~ ! *(команда)* кыскарак атла!
полный ~ ! *(команда)* тулы атла!
чаще ~ ! *(команда)* ешрак атла!
шире ~ ! *(команда)* киңрәк атла!
беглый ~ тиз-тиз атлау
~ **винта** винт адымы *(бер тулы әйләнеш вакытында винт сызыгының күтәрелү биеклеге)*
~ **гусеницы** тәгәрмәч чылбыры адымы
~ **минирования** мина кую адымы
~ **обмотки** чорналма адымы
~ **прицела** төзәгеч адымы
~ **резьбы** винт сыры адымы
строевой ~ саф адымы
чеканить ~ шак-шак атларга, шакылдатып атларга
шагом! *(команда)* атлап!
шагом марш! *(команда)* атлап марш!
шагомер *м* адым үлчәгеч *(винт сыры яки тешле тәгәрмәч адымын үлчәгеч прибор)*
шайба *ж* шайба
замковая ~ йозак шайба *(гайка борылып чыкмасын өчен кулланыла)*
шанец *м уст.* шанец *(XVII—XIX гасырларда Россиядә вакытлы кыр ныгытмаларының гомуми исеме)*
шанцев//ый шанец ...ы, е
~ **ая лопата** шанец көрәге
~ **ый инструмент** шанец коралы *(окоплар, траншеялар һ.б. төзү өчен хезмәт итә торган кораллар)*
«шапками закидать» бүрек белән бәреп егырга *(дошманны җиңүгә җиңел караш)*
шапка-ушанка колакчынлы бүрек
шар *м* шар
воздушный ~ һава шары
~ **-зонд** *м* шар-зонд *(автоматик приборлар ярдәмендә югары атмосфераны тикшерү өчен җибәрелә торган һава шары)*
шарнир *м* шарнир, тупса
шаровидный шарсыман
шасси *с* шасси *(1. очкычның тәгәрмәчләр яки чаңгылар урнашкан рамы 2. кайбер машиналарның нигезен тәшкил итә торган рам)*
выпускать ~ шасси чыгарырга
неубирающееся ~ җыелмый торган шасси
шатер *м* чатыр
шатун *м* шатун *(пешкәкне двигательнең терсәкле валы белән тоташтыра торган деталь)*
шахтовая пусковая установка шахтадан җибәрү җайланмасы *(җир асты тибындагы сугышчан ракета комплексының төп корылмасы)*
шашка I *ж* шашка
дымовая ~ төтен шашкасы
запальная ~ кабызу шашкасы
трубчатая пороховая ~ көпшәсыман дары шашкасы
ядовито-дымная ~ агулы төтен шашкасы
шашка II *ж* кылыч, шашка
швартов *м* швартов, бәйләү арканы
отдать ~ **ы** швартовны ычкындырырга
швартоваться *мор.* арканлап куелырга
швермер *м* швермер *(фейерверк ракетасы)*
шеврон *м* шеврон *(1. солдат һәм кече офицерларның сул җиңендәге хәрби хезмәт срогыннан тыш ничә ел хезмәт итүен белдерә торган почмак формасындагы билге 2. яраланган булуны белдереп уң күкрәккә тегелә торган кызыл яки алтынсу билге)*
шептало *с* шептало, тоткыч *(курокны сугышчан һәм сакланыш хәлләрендә тоту өчен хезмәт итә)*
шеренг//а *ж* шеренга *(бер-берсенә яны белән басып бер сафка тезелгән кешеләр рәте)*
в две ~ **и становись!** *(команда)* ике рәткә бас!
в одну ~ **у становись!** *(команда)* бер рәткә бас!
выстроиться в две ~ **и** ике рәткә тезелергә

шестерня *ж* шестерня *(тешле тәгәрмәч)*
ведомая ~ йөртелүче шестерня
ведущая ~ йөртүче шестерня
коническая ~ конуссыман шестерня
паразитная ~ паразит шестерня *(хәрәкәтне бер шестернядан икенчесенә күчерә)*
шибер *м* *(задвижка)* эшермә
шинель *ж* шинель
парадно-выходная ~ парад-бәйрәм шинеле
ширина *ж* киңлек, иң
габаритная ~ габарит иңе
~ **строя** саф киңлеге
широта *ж* киңлек
географическая ~ географик киңлек *(җир өстендәге ноктаның урынын билгели торган координатларның берсе)*
ширстрек *м* ширстрек *(судно корпусы тышлыгының өске поясы)*
шифр *м* шифр *(яшерен язу өчен шартлы билгеләр)*
~ **опознавательных сигналов** тану сигналлары шифры
шифратор *м* шифратор
шифровальщик *м* шифрлаучы
шифровать шифрларга, шифр белән язарга
шифровка *ж* шифрлы язу
шишак *м* шишак *(шлем төре — борынгы баш киеме)*
шкала *ж* шкала *(приборның сан-дәрәҗә күрсәткеч бүлемнәре)*
~ **высот** биеклек шкаласы
шкафут *м* шкафут *(судноларда югары палубаның фок-мачта һәм грот-мачта арасындагы өлеше)*
шквал *м* өермә, давыл
~ **огня** ут өермәсе
артиллерийский ~ артиллерия гарасаты
шквальный 1. өермәле, давыллы 2. *күч.* дәһшәтле, гарасатлы
шкив *м* шкив *(механизмнарда күчергеч каешны кидертә торган тәгәрмәч)*
шкипер *м* шкипер *(1. хәрби корабларда яки зур сәүдә судноларында палуба әйберләре өчен җаваплы кеше 2. үз двигателе булмаган тагылма судно — баржа командиры)*
школ//а *ж* 1. мәктәп 2. тәҗрибә
войсковая ~**а** гаскәри мәктәп
~**а младших специалистов** кече белгечләр мәктәбе
летная ~**а** очучылар мәктәбе
офицерская ~**а** офицерлар мәктәбе
специальная ~**а** махсус мәктәп
техническая ~**а** техник мәктәп
пройти хорошую ~**у в армии** армиядә яхшы мәктәп узырга
шкот *м* шкот *(җилкәнне киерү һәм идарә итү баулары)*
шлагбаум *м* шлагбаум *(заставада яки тимер юл үткелләрендә юлны ачуябу өчен кулланыла торган киртә)*
шлем *м* шлем, башлык *(1. металлдан эшләнгән очлы түбәле борынгы хәрби баш киеме 2. очучылар, танкистлар кия торган махсус баш киеме 3. кешенең башын тышкы тирәлек йогынтысыннан саклау өчен махсус баш киеме)*
водолазный ~ водолаз шлемы
пробковый ~ бөке шлем
шлемофон *м* шлемофон *(очучылар, космонавтлар, танкистлар һ.б. кия торган, сөйләшү җайланмасы булган шлем яки шлем формасындагы сөйләшү җайланмасы)*
шлюз *м* шлюз *(төрле биеклектә булган сулыкларның берсеннән икенчесенә судноларны үткәрү өчен аерым камералары булган гидротехник корылма)*
шлюп *м* шлюп *(1. XVIII—XIX гасырларда туры җилкәнле, өч мачталы кораб 2. ике җилкәнле, бер мачталы диңгез судносы)*
шлюпка *ж* шлюпка *(палубасыз, ишкәкле, җилкәнле һәм моторлы кечерәк судноларның уртак исеме)*
складная ~ җыелмалы шлюпка
спасательная ~ коткару шлюпкасы
шнур *м* шнур *(бау яки үткәргеч)*
запальный ~ яндыру шнуры
спусковой ~ ычкындыргыч шнур
шомпол *м* шомпол *(1. мылтык һ.б. ату коралы көпшәсен чистарту һәм майлау өчен яки көпшәдән корыла торган мылтыкларга һәм пистолетларга заряд тутыру өчен хезмәт итә торган саплы тимер чыбык)*
шпалер//ы *мн.* шпалер, ике саф, ике рәт
солдаты стоят ~**ами** солдатлар ике саф булып торалар
шпангоут *м* шпангоут *(очкыч яки судно корпусына ныклык бирү өчен куелган аркылы борыс)*

шпиль *ж мор.* шпиль *(судноларда якорь төшерү-күтәрү яисә йөк төяү өчен хезмәт итә торган чыгыр)*
шпиндель *м* шпиндель, күчәр
шпион *м* шпион
шпионаж *м* шпионлык *(нинди дә булса бер ил разведкасына хезмәт итү, аның өчен дәүләт сере итеп саклана торган белешмәләр җыйнау, һәртөрле корткычлык ясау кебек җинаять эшчәнлеге)*
шпицрутен *м* шпицрутен *(патша армиясендә тән җәзасы бирү өчен кулланылган озын сыек чыбык)*
шпора *ж* шпор *(атны әйдәү өчен кавалеристларның күн итек үкчәсенә беркетелгән тешле яки шома тәгәрмәчле тимер дуга)*
шрапнель *ж* шрапнель *(дошманның ачык җирдә урнашкан җанлы көчләрен юк итү өчен кулланылучы, эченә пулялар тутырылган артиллерия снаряды)*
штаб *м* штаб *(командалыкның гаскәр белән җитәкчелек итү органы; шул орган урнашкан бина)*
~ **армии** армия штабы
вышестоящий ~ югарыгы штаб
~ **военного округа** хәрби округ штабы
генеральный ~ генераль штаб
главный ~ баш штаб
штабн//ой 1. штаб ...ы, е 2. штабчы *(штабта хезмәт итүче)*
~**ая рота** штаб ротасы
штандарт *м* штандарт *(патша һәм кайбер чит ил армияләренең кавалериясендә полк байрагы)*
штат *м* штат *(берәр учреждениедә эшләүчеләрнең даими составы)*
~**ы военного времени** сугыш вакыты штатлары
штатн//ый штаттагы
~**ое расписание** штат расписаниесе *(хәрби частьтагы, учреждениедәге, уку йортындагы хезмәткәрләрнең рөхсәт ителгән составын һәм санын билгеләүче рәсми документ)*
штатский штатский *(хәрби булмаган)*
штиль *м* штиль *(җилсезлек)*
штопор *м* штопор *(авиациядә югары пилотаж фигураларының берсе — очкычның текә спираль ясап түбәнәюе; очкычның идарә югалу сәбәпле үз көчәрендә әйләнеп бик тиз түбән төшүе)*

шторм *м* шторм, давыл
шторм-трап *м* шторм-трап *(диңгез өсте давыллаганда кешеләрне судногa алу яки төшерү өчен баудан эшләнгән трап)*
штормить давылларга
штормов//ой шторм ...ы, е; давыл ...ы, е; штормлы, давыллы
~ **ая погода** давыллы һава
~ **ое предупреждение** давыл кисәтүе
~ **ой якорь** шторм якоре
штраф *м* штраф *(берәр эшне төгәл үтәмәгән яки кагыйдә бозган өчен бирелә торган җәза)*
штрафн//ой штраф ...ы, е
~ **ой батальон** штраф батальоны *(гаепле табылган хәрби кешеләр өчен махсус дисциплинар батальон)*
~ **ая часть** штраф часте
штурвал *м* штурвал
штурм *м* штурм, штурмлау *(дошманның крепостена, ныгытмаларына яки терәк пунктына халиткеч атака)*
взять ~ **ом** штурм белән алырга
идти на ~ штурмга барырга
штурман *м* штурман *(корабларны, очкычларны төгәл маршрут белән йөртүче белгеч)*
штурмовик *м* штурмовик *(сугыш кырында дошман көчләренә каршы зур булмаган биеклектән һөҗүм итә торган хәрби очкыч)*
штуцер *м* штуцер *(1. сырлы көпшәле борынгы заман мылтыгы. XIX гасырда бөтен армияләрдә дә винтовкага алмаштырылган. Хәзерге вакытта эре калибрлы сырлы көпшәле ау мылтыгы 2. торбаларны бер-берсенә яки резервуарга борып беркетү өчен тышкы ягы сырлап эшләнгән торба кисәге)*
штык *м* штык *(кул сугышы өчен мылтык, автомат көпшәсенең очына кидерелә торган салкын корал)*
колоть ~ **ом** штык белән чәнчергә
пойти (идти) в ~ **и** штыкка-штык барырга
отряд в тысячу ~ **ов** мең штыклы отряд
держаться на ~ **ах** штык ярдәмендә торырга, гаскәр көче белән торырга
~ **примкнуть!** *(команда)* штык кидер!
штык-юнкер *м* штык-юнкер *(XVIII га-*

сырда Россиядә кече артиллерия офицеры чины)

шумопеленгатор *м* тавыш пеленгаторы

шутиха *ж* шутиха *(зигзаг ясаучы фейерверк ракетасы)*

шхуна *ж* шхуна *(ике яки күбрәк мачталы җилкәнле кораб)*

Щ

щека *ж* 1. янак 2. елганың текә яры
 ~ **клина** чөй янагы
 ~ **цевья** көбәк янагы

щелочь *ж* селте

щель *ж* 1. ярык 2. яшеренү урыны, саклану урыны
 крытая ~ ябулы яшеренү урыны
 смотровая ~ күзәтү ярыгы

щетка *ж* щетка *(коллекторлы электр машиналарында якорьдан коллекторга килгән токны тышкы чылбырга яки тыштан килгән токны якорьга күчерә торган деталь)*

щит *м* калкан

щиток *м* битлек, панель, такта
 ~ **приборов** прибор тактасы, прибор панеле

щуп *м* капшавыч
 разведка мин ~**ом** миналарны капшавыч белән эзләү

Э

эбонит *м* эбонит *(каучуктан күкерт катнаштырып әзерләнгән, кислотага, селтегә, суга бирешми торган каты диэлектрик матдә)*

эвакогоспиталь *ж* эвакуация госпитале *(сугыш вакытында эвакуацияләнеп килгән авыруларны һәм яралыларны дәвалый торган госпиталь)*

эвакопункт *м* эвакуация пункты, эвакопункт

эвакуация *ж* эвакуация, эвакуацияләү

эвакуировать эвакуацияләргә

эдикт *м ист.* эдикт, фәрман

эжектор *м* эжектор *(1. эжекциядән файдалануга нигезләнгән җайланма 2. ату коралында затворны ачканда атылган патрон гильзасын автоматик чыгарып ташлый торган механизм 3. һава яки пар агымы җибәрү юлы белән мылтык көпшәсе каналын дары газларыннан чистарта торган прибор)*

эжекция *ж* эжекция *(нинди дә булса ике матдәнең: пар белән суның, су белән комның һ.б. кушылу процессы; бу очракта бер матдә басым астында булып, икенчесен үзенә ияртә)*

экипаж *м* экипаж

экипировка *ж* 1. экипировка *(кирәк-ярак белән тәэмин ителү)* 2. кирәк-ярак 3. кием-салым

эклиметр *м* эклиметр *(җир өстенең авышлык почмагын үлчи торган геодезия приборы)*

эклиптика *ж* эклиптика *(күк сферасында кояшның еллык хәрәкәтен күрсәтүче уйланма сызык)*

экономайзер *м* экономайзер *(карбюраторда дроссель каплавычы тулысынча яки тулысынча диярлек ачык вакытта ягулык катнашмасын баету өчен хезмәт итә торган җайланма)*

экономика *ж* экономика, икътисад

экран *м* экран, пәрдә, чаршау
 ~ **индикатора** индикатор экраны

экспедиция *ж* экспедиция
 военная ~ хәрби экспедиция *(хәрби отрядның махсус задание, максат белән походы; шундый походта катнашучылар отряды)*

экспансия *ж* экспансия *(1. экономик-сәяси ысуллар белән бер дәүләтнең яки экономик төркемнең йогынты сферасын киңәйтү күренеше 2. яңа җирләр басып алуга омтылыш)*
 военная ~ хәрби экспансия *(башка халыкларны сәяси һәм экономик кабалага төшерү, үз хәрби-стратегик хәлен ныгыту максатында коралды юл белән чит җирләрне басып алу)*

экспертиз//а *ж* экспертиза
 военно-врачебная ~**а (ВВЭ)** хәрби медицина экспертизасы
 врачебная ~**а** медик экспертиза
 произвести ~**у** экспертиза ясарга
 техническая ~**а** техник экспертиза

эксплуатация *ж* файдалану, эксплуатация
 ~ **машины** машинаны файдалану

электровзрыватель *м* электр шартлаткычы

электровоспламенитель *м* электр кабызгычы

электродетонатор *м* электр детонаторы
 ~ **замедленного действия** сагайтулы, вакытка куелган электр детонаторы

электрозапал *м* электр кабызгычы
элемент *м* элемент, өлеш, кисәк
электронагревательный ~ электр белән җылыту элементы
элерон *м* элерон *(горизонталь очканда һәм борылган вакытта очкычны янтайтмас өчен хезмәт итә торган һәм канатларга шарнир ярдәмендә беркетелгән җайланма)*
эллинг *м* эллинг *(диңгез, елга, күл буенда судноларр төзү һәм ремонтлау өчен билгеләнгән, шулай ук авыш яссылык буенча судноларны судан күтәрү яки суга төшерү өчен җайланган корылма)*
эмблема *ж* эмблема *(берәр төшенчәне яки идеяне шартлы рәвештә белдерә торган символик әйбер, сурәт, күренеш)*
~ **рода войск** гаскәр төре эмблемасы
энергия *ж* 1. энергия *(җисемнең яки җисемнәр системасының эш башкару сәләтен характерлаучы зурлык)* 2. энергия, дәрт, гайрәт, куәт, көч
атомная ~ атом энергиясе *(атом төшләре үзгәреше вакытында атомның чыгара яки йота торган энергиясе)*
внутриядерная ~ төшнең эчке энергиясе
лучевая ~ нур энергиясе
тепловая ~ җылылык энергиясе
ядерная ~ атом-төш энергиясе
эпицентр *м* эпицентр *(нинди дә булса процессның үзәге)*
~ **ядерного взрыва** атом-төш шартлавы эпицентры
эполеты *мн* эполетлар *(патша армиясендә офицерның парад формасындагы чачаклы погоннар)*
эскадра *ж* эскадра *(хәрби-диңгез судноларының һәм һава флоты очкычларының зур берләшмәсе)*
эскадрилья *ж* эскадрилья *(хәрби авиациядә очкычларның берничә звеносыннан торган берләшмә)*
эскадрон *м* эскадрон *(атлы гаскәрнең җәяүле гаскәрдәге ротага туры килә торган бүлекчәсе)*
эскалация *ж* эскалация, үсү, киңәю
~ **военных действий** хәрби хәрәкәтләрнең киңәюе
эскарп *м* эскарп *(1. хәрби ныгытмадагы тышкы як чокырның арткы сөзәк стенасы 2. танкка каршы хәрби ныгытманың дошман ягына караган ягындагы бик текә стенасы)*
эскорт *м* эскорт *(кемне яки нәрсәне дә булса саклауда яки озатуда хәрби конвой, хәрби сакчылар отряды)*
эскортировать эскорт белән алып барырга
эсминец *м* эсминец *(эскадра миноносецы)*
эспадрон *м* эспадрон *(тупыйк очлы кылыч)*
эстакада *ж* эстакада *(юлларны югары күтәртү, аркылы чыгып йөрү өчен, шулай ук судноларр килеп туктау яки нәрсәне дә булса төяү-бушату өчен салынган күперсыман корылма)*
этап *м* этап *(бер җирдән икенче җиргә күчкәндә хәрби хезмәткәрләрне фатир, азык-төлек һ.б. белән тәэмин итә торган пункт)*
эфес *м* эфес *(кылыч, хәнҗәр һ.б. салкын коралның сабы)*
эффект *м* эффект, нәтиҗә, йогынты, тәэсир
~ **Допплера** Допплер эффекты *(тирбәнеш чыганагы белән алгыч арасындагы ераклык үзгәреп торганда кабул ителгән ешлыкның чыккан ешлыкка карата үзгәрү күренеше)*
кумулятивный ~ кумулятив эффект *(шартлау көче тәэсирен билгеләнгән юнәлештә туплау)*
эхолот *м* эхолот *(диңгез тирәнлеген үлчәгеч)*
эшафот *м* эшафот *(үлем җәзасын башкару өчен ясалган махсус күтәрмә)*
эшелон *м* эшелон *(1. сугыш тәртипләрендә эчкә табан бер-бер артлы урнаштырылган берләшмәләр, подразделениеләр 2. махсус йөк яки кешеләр төяп бара торган тимер юл составы, автоколонна, очкычлар төркеме)*
воинский ~ гаскәри эшелон
железнодорожный ~ тимер юл эшелоны
походный ~ поход эшелоны
эшелонировать эшелонлаштырырга, эшелон-эшелон итеп урнаштырырга

Ю

юбка порщня пешкәк итәге
юзом *нареч.* 1. естерәп, сөйрәп 2. шуып, тәгәрәмичә шуып

передвигать груз ~ йөкне сөйрәп күчерергә

задние колеса шли ~ арткы тәгәрмәчләр шуып барды

юлить әйләнергә, бөтерелергә, тулганырга

юнга *м* юнга *(матрос булырга әзерләнүче һәм диңгез эшләренә өйрәнүче яшүсмер)*

юнкер *м* юнкер *(патша Россиясендә хәрби училищеда укучы, 1864—1910 елларда юнкерлар училищесында тәрбияләнүче; яшь офицер; курсант)*

юпитер *м* юпитер *(бик көчле яктырткыч прибор)*

юриспруденция *ж* юриспруденция, хокук фәне

юрист *м* юрист *(хокук белгече)*

юрисконсульт *м* юрисконсульт *(хокук киңәшчесе)*

юркость *ж* елгырлык, елдамлык

юрта *ж* тирмә *(киез өй)*

юстировка *ж* юстировка *(үлчәү чараларының — башлыча оптик приборларның — төгәлсезлекләрен табу, аларны төзәтү һәм тиешле техник таләпләргә туры китерү)*

юстиция *ж* юстиция *(хокук һәм гадел хөкем чыгару эшләре, суд учреждениеләре системасы)*

ют *м* ют *(корабның югары палубасының арткы өлеше)*

Я

явка *ж* 1. килү 2. яшерен очрашу урыны

являться 1. килергә, килеп җитәргә, кайтырга, кайтып җитәргә 2. булырга, булып торырга

~ на место расположения роты рота урнашкан җиргә килергә (кайтырга)

явление *с* күренеш, хәл

яд *м* агу

ядерн//ый төш ...ы, е; атом-төш ...ы, е

~ая реакция атом-төш реакциясе

~ая энергия атом-төш энергиясе

~ое оружие атом-төш коралы

~ый реактор атом-төш реакторы

ядро *с* 1. төш, үзәк 2. ядрә

~ атома атом төше

язва *ж* эренле яра, җәрәхәт

сибирская ~ түләмә

язык *м* тел

захватить ~а тел эләктерергә *(сугышта дошман серләрен, дошман якның хәлен белү өчен кулга махсус әсир төшерергә)*

якор//ь *м* якорь

бросить ~ь якорь ташларга

выбирать ~ь якорьны алырга, якорьны күтәрергә

отдать ~ь якорьны төшерергә

плавучий ~ь йөзмә якорь

сняться с ~я якорьдан алынырга

стоять на ~е якорьда торырга

ял *м* ял *(2—8 ишкәкле каек)*

яма *ж* 1. чокыр, баз 2. инкүлек, иңкү урын, уйсулык, уйсу урын

воздушная ~ һава чокыры

янычар *м* янычар *(солтан Төркиясендә хәрби әсирләрдән һәм мөселманлыкка күчерелгән христианнардан тупланган регуляр җәяүле гаскәр солдаты)*

ясырь *м* әсир

ятаган *м* ятаган *(борынгы кәкре хәнҗәр)*

яхта *ж* яхта *(моторлы яки җилкәнле кечкенә судно)*

ячейка *ж* 1. ячейка *(бер укчы өчен ясалган кечкенә окоп)* 2. күзәнәк

ящик *м* әрҗә, тартма

«черный ~» «кара тартма» *(бик нык материалдан эшләнгән, эчендә очкычның ничек очуы турында язып баручы магнитофоны булган мәгълүмат җыйгыч савыт. Гадәттә очкычның койрык өлешенә урнаштырыла. Авиаһәлакәтнең сәбәбен ачыклауда файдаланыла)*

Условные сокращения военных терминов
Хәрби терминнарның шартлы кыскартмалары

А армия ***армия (А)***

АА атомная артиллерия ***атом артиллериясе***

аад армейская артиллерийская дивизия ***армиянең артиллерия дивизиясе***

ААС армейский артиллерийский склад ***армиянең артиллерия склады***

АБ атомная бомба ***атом бомбасы***

АБ(к) атомная бомба крупного калибра ***эре калибрлы атом бомбасы***

АБМ артиллерия большой мощности ***зур куәтле артиллерия***

АВ авианосец ***авианосец***

АВС армейский вещевой склад ***армиянең әйберләр склады***

автб автомобильный батальон ***автомобиль батальоны***

автбр автомобильная бригада ***автомобиль бригадасы***

автв автомобильный взвод ***автомобиль взводы***

автп автомобильный полк ***автомобиль полкы***

автр автомобильная рота ***автомобиль ротасы***

АВФ автоматическое выравнивание фазы ***фазаны автоматик тигезләү***

АГ авиационный госпиталь ***авиация госпитале***

АГВ автодегазационная станция горячим воздухом ***кайнар һава белән автодегазацияләү станциясе***

АГЛР армейский госпиталь для лечения легкораненых ***җиңел яралыларны дәвалау өчен армия госпитале***

АГСМ авиационные горюче-смазочные материалы ***авиация ягулык-майлау материаллары***

АГШ академия генерального штаба ***генераль штаб академиясе***

ад артиллерийская дивизия ***артиллерия дивизиясе***

АДД артиллерия дальнего действия ***еракка ата торган артиллерия***

адд авиадесантный дивизион ***авиадесант дивизионы***

АДК артиллерийский дегазационный комплект ***артиллериянең дегазация комплекты***

АДМ автодегазационная машина ***автодегазация машинасы***

адн артиллерийский дивизион ***артиллерия дивизионы***

АЗАГ армейская зенитная артиллерийская группа ***армиянең зенит артиллериясе төркеме***

АЗП автоматическая зенитная пушка ***автоматик зенит тубы***

АЗС автозаправочная станция ***автомобильләргә ягулык салу станциясе***

АЗС аккумуляторно-зарядная станция ***аккумулятор кору станциясе***

АИРБ армейская инженерная ремонтная база ***армиянең инженерлык-ремонт базасы***

аисбр армейская инженерно-саперная бригада ***армиянең инженерлык-сапер бригадасы***

ак армейский корпус ***армия корпусы***

ак авиационный корпус ***авиация корпусы***

АКС аппаратура контроля стрельбы ***атуга контроль аппаратурасы***

АЛ автолаборатория ***автолаборатория***

АМ атомная мина ***атом минасы***

амб артиллерийская метеорологическая батарея ***артиллериянең метеорологик батареясы***

АМОВД аэродром материального обеспечения воздушного десанта ***һава десантын матди тәэмин итү аэродромы***
АМП артиллерийский метеорологический планшет ***артиллерия өчен метеорологик планшет***
АМП артиллерийский метеорологический пост ***артиллериянең метеорологик посты***
АМС артиллерийская метеорологическая сводка ***авиация өчен метеорологик белешмә***
АМС авиационная метеорологическая станция ***авиациянең метеорологик станциясе***
АМС артиллерийская метеорологическая служба ***артиллериянең метеорологик службасы***
АМС артиллерийская метеорологическая станция ***артиллериянең метеорологик станциясе***
АНО аэронавигационный огонь ***аэронавигация уты***
АО атомное оружие ***атом коралы***
ао авиационный отряд ***авиация отряды***
АОН авиация особого назначения ***махсус авиация***
АОН артиллерия особого назначения ***махсус артиллерия***
АОО аэродромное осветительное оборудование ***аэродромны яктырту җиһазлары***
АП автопилот ***автопилот***
АП антенный переключатель ***антенна күчергече***
ап авиационный полк ***авиация полкы***
ап артиллерийский полк ***артиллерия полкы***
АПБНП артиллерийский подвижный бронированный наблюдательный пункт ***артиллериянең броняны күчмә күзәтү пункты***
апбо артиллерийский полк береговой обороны ***яр буе оборонасының артиллерия полкы***
